ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТИ АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# «ӘДӘБИЯТ» ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## Татар әдәбияты буенча башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр

Казан
2014

**ББК 74. 268. 3 Тат**
**Ә 26**

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп, Өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләти автономияле мәгариф оешмасы «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»ның редакцияләү, нәшер итү советы карары нигезендә басыла*

**Проект җитәкчеләре:**
**Р.Г.Хәмитов,** өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләти автономияле мәгариф оешмасы «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Л.Ф.Салихова,** өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләти автономияле мәгариф оешмасы «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»ның укыту-методик эшләр буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты
**Фәнни мөхәррир:**
**В.И.Пискарев,** өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләти автономияле мәгариф оешмасы «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»ның мәгариф стратегиясе һәм үсеш программалары бүлеге мөдире, тарих фәннәре кандидаты
**Төзүче:**
**М.Г.Мозаффарова,** милли мәгариф лабораториясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты

«Әдәбият» предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр / М.Г.Мозаффарова. – Казан. – ТР Мәгарифне үстерү институты. – 80 бит.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә куюга әзерлек чорында, гомуми белем бирү оешмаларында татар әдәбиятын укыту мәсьәләләренә бер караш. «Нәрсә эшләргә тиешбез? Ничек?» – классик сораулар тирәсендә фикер уртаклашу. Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларының үзенчәлеген ассызыклау, көтелгән нәтиҗәлелекне тәэмин итүче факторларны барлау һәм планлаштыру, танып белү эшчәнлеге эффективлыгын тәэмин итү ысулын тәкъдим итү.

© ТРМҮИ, 2014

**ЭЧТӘЛЕК**

Норматив-хокукый документлар / Нормативно-провавые документы........................................................................................4
Бу хезмәттә белем бирүдә федераль дәүләт стандартларына бәйле кулланылган төшенчәләр сүзлекчәсе......................................5
Россия Федерациясе мәгарифе системасын яңарту (модернизация) кысаларында «Әдәбият – Литература» предметын укытуга таләпләр үзенчәлеге...........................................................................5
Татар әдәбиятын укытуда инновацион эшчәнлек оештыру буенча тәкъдимнәр:
1.Максатка ярашлы укыту-методик комплектларына заказ формалаштыру буенча тәкъдим...........................................................8
2.«Әдәбият» дәресләрдә танып белү эшчәнлеген оештыру буенча тәкъдим.................................................................................15
3.«Әдәбият» предметы буенча күтелгән нәтиҗәлелекне планлаштыру буенча тәкъдим..........................................................20
Кушымталар....................................................................................27
1. Белем бирү федераль дәүләт стандартларында кулланылган төшенчәләрнең рус һәм татар телләрендә аңлатмалы сүзлеге.............27
2.Иҗади үсеш технологиясенә корылган дәрес эшкәртмәсе...30
3. «Әдәбият» предметы буенча эш программасы төзегәндә файдалану өчен...........................................................................36
а) Башлангыч сыйныфта А.Яхин программасы нигезендә төзелгән эш программасы (төзүче - М.Г.Мозаффарова)
ә) А.Яхин программасы нигезендә төзелгән эш программасы (5 сыйныф.Төзүче – Р.Г.Хәсәншина, Яр Чаллы шәһәре, 52 нче мәктәпнең югары квалмфикация категорияле укытучысы
Кулланылган чыганаклар исемлеге ........................................77

## Норматив–хокукый документлар /
## Нормативно-провавые документы

**Россия Федерациясе тарафыннан кул куелган халыкара килешүләр -** Международные документы, подписанные Российской Федерацией:

- «Бала хокуклары турындагы ковенция» - «Конвенция о правах ребенка» Берләшкән милләтләр оешмасы генераль Ассамблеясе тарафыннан ( 44/ 45 нче резолюциясе нигезендә) 1989 нчы елның 20 нче ноябрендә кабул ителә, 1990 нчы елның 13 нче июнендә СССР Югары Советы тарафыннан раслана (ратификацияләнә) һәм 1990 нчы елның 15 нче сентябреннән Россия Федерациясендә дә гамәлгә куела.

**Россия Федерациясе законннары -** законы Российской Федерации:

- «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» «О языках народов Российской Федерации»;
- «Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон - ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» ( 2012 нче елның 29 нчы декабрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013 нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә);

**Татарстан Республикасы законнары** - Законы Республики Татарстан:

- «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан», «ТР дәүләт телләре һәм ТРсындагы башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы законы;
- Закон Республики Татарстан «Об образовании» - «Мәгариф турында»гы Татарстан Республикасы законы (№ 68, 2013 нче елның 22 нче июле);
- «Государственая программа Республики Татарстан «Сохранение, изучение и развитие языков РТ и других народов в Республике Татарстан на 2014–2020 годы» - «2014-2020 нче елларда ТРсы дәүләт телләрен һәм ТРның башка халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТРсы дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 нче елның 25 нче октябреннән 794 нче карары).

**Искәрмә:**

Бу хезмәттә кулланышка керәчәк төп педагогик төшенчәләр сүзлекчәсе:

белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары – федеральные государственные образовательные стандарты

махсус белем – специальное знание

махсус күнекмә – специальное умение

тотрыклы күнекмә – навык

белем алуда универсаль гамәлләр – универсальные учебные действия

рухи-әхлакый үсешне күрсәтүче гамәлләр – личностные действия

регулятив гамәлләр – регулятивные действия

танып белү гамәлләре – познавательные действия

коммуникатив гамәлләр – коммуникативные действия

## Россия Федерациясе мәгарифе системасын яңарту (модернизация) кысаларында «Әдәбият - Литература» предметын укытуга таләпләр үзенчәлеге

Хөрмәтле коллега, гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше концепциясе укыту-тәрбия процессының эчтәлеген дә, укучының танып белү эшчәнлеген оештыру характерын да, димәк, укытучыга үз эшчәнлеген тамырдан үзгәтрүне таләп итә.

Гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше концепциясе «Литература- Әдәбият» предметын укытуның төп максатын түбәндәгечә ассызыклый:

- әсәрне укый белү күнекмәсе формалаштыру;
- әсәргә комментарий бирә һәм анализ ясый, бәя бирә белү күнекмәсе формалаштыру;
- үз текстын төзи белү күнекмәсе формалаштыру ( иҗади фикер эшчәнлеген үстерү).

(Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В.В.Козлова, А.М.Кондакова. – М.: Просвещение, 2009, 14 бит).

«Литература – Әдәбият» предметы эчтәлеге

— сүз тудырылган образ сәнгате буларак әдәбият;

— әсәр тудырган дөнья: әдәбиятның «мәңгелек» темасы, социаль, фәлсәфи, рухи-әхлакый проблема чишелеше ачылу зарурлыгы;

— әдәби сөйләм;

— әдәби төрләр һәм жанрлар;

— әдәби процесс- әдәбиятның үсеш тарихы

(Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В.В.Козлова, А.М.Кондакова. – М.: Просвещение, 2009, 14-16 нчы битләр).

(*Искәрмә:* Теоретик белем фундаменталь – барлык милләт әдәбияты өчен дә уртак, ә менә «мәңгелек» темасы, күтәрелгән проблемалар, аларны чишү юллары – фәлсәфәсе, әдәбиятның үсеш тарихы үзенчәлекле булырга мөмкин. Дәреслек авторлары да, дәреслекләрне сайлап алырга бурычлы һәм хокуклы татар әдәбиятын укытучылар да бу мизгелне нечкә тоемлап, акыллы эш итәргә тиеш).

**Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларының үзенчәлеге һәм « Әдәбият» предметы**

- укучы үзләштерергә тиешле белемнең фундаменталь булу зарурлыгы. Ягъни Россия Федерациясенең теләсә кайсы төбәгендә урнашкан һәм нинди төр белем бирү оешмасында (авыл мәктәбендә яисә шәһәр мәктәбендә, гимназиядә яисә лицейда) укуына карамастан үзләштерелергә тиешле махсус белем, күнекмәләр эчтәлеге һәм сыйфаты ягыннан бер үк дәрәҗәдә булырга тиешлек;
- бүгенге укучы – киләчәк кешесе формалашуы өчен мөһим, актуаль мәгълүмат бирелү;
- белем алуда универсаль гамәлләрнең

1) предметара гамәлләрнең:

а) регулятив гамәлләр формалашуы – уку мәсьәләсен кую (мин нишләргә тиеш? дип уйлый белү); чишү юлларын билгеләү (ничек эшләп була? болай да, болай да була, тагын башкача эшләп

булмыймы икән? дип уйлый белү); эффектив булганын (нәтиҗәгә җиңел илтә торганын, уңаен) сайлап ала алу; куелган мәсьәләне чишү; үз эшенә контроль ясый (нишләргә тиеш идем әле, ничек эшләдем? дип кабат уйлый) белү һәм үз эшенә адекват бәя бирә (ничек булды? куелган максатка ирештемме? ни дәрәҗәдә ирештем? яки яхшымы, начармы? дигән сорауларга җавап бирә) белү ;

б) танып белү гамәле – ысул белән коралландыру – укучыда нинди генә эшкә тотынса да эшләү ысулын аерып алу ихтыяҗы һәм күнекмәсе формалаштыру. Димәк, теләсә кайсы әдәби төр һәм жанрны, әдәбият тарихын үзләштерү ысулы, төрле белем чыганакларыннан файдалана белү күнекмәсе үсеше һәм эчтәлекне модельләштерә (башкарылган эшнең кыскача, яки схемада язылышы) белү зарурлыгы;

в) коммуникатив гамәлләр үсеше (укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әдәп, әхлак кысаларында әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп татар әдәби телендә җиткерә белү) - әсәрне укыганда геройларның гамәлләренә, сөйләгән сүзләренә, аларның әйләнә-тирәдәгеләргә йогынтысына (башка геройларга) бәя бирүе;

2) рухи-әхлакый үсешне күрсәтүче гамәлләрнең (игътибарлылык, итәгатьлелек, зирәклек, гомумкешелек кыйммәтләренә матур мөнәсәбәт кебек шәхеснең интеллектуаль, эмоциональ, социаль һәм әхлакый үсеш дәрәҗәсен билгели торган гамәлләр) тотрыклы формалашуы өчен җирлек булдырылу зарурлыгы;

- махсус белем һәм күнекмәләр, универсаль гамәлләр формалаштыруда дәвамчанлык принцибы сакланышы

(балалар бакчасы һәм беренче сыйныф, 1– 2, 2-3, 3-4 сыйныфлар арасында; гомуми башлангыч белем бирү баскычы һәм V сыйныф, 5-6,6-7, 7-8, 8-9 сыйныфлар арасында; гомуми төп белем бирү баскычы белән X сыйныф һәм гомуми урта белем бирү баскычы арасында; татар милли мәгърифәтчелек идеяләре һәм бүгенге заман таләпләре - белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары яссылыгында)

## Татар әдәбиятын укытуда инновацион эшчәнлек оештыру буенча тәкъдимнәр

### 1. Максатка ярашлы укыту-методик комплектларына заказ формалаштыру буенча тәкъдимнәр

**1.1.Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары таләп иткән дәвамчанлык принцибын тәэмин итү буенча тәкъдим .**

Мәгълүм булганча, белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары Концепциясе озак еллар дәвамында сыналган һәм танылган үстерешле укыту системасы казанышларына таянып эшләнде. Бу – галимнәребезнең уку-укыту системасын яңарту мөһимлеген белдереп чаң сугуларын, ниһаять, рәсми хакимият ишетте; ниһаять, дәүләт белән галимнәрнең, мәгърифәтчеләрнең фикере тәңгәл килде, дигән сүз.

Еллар аша үткәнгә күз салыйк. Дөньякүләм билгеле галимнәр һәм рус галимнәре янәшәсенә куела алган татар мәгърифәтчеләренең кайберләрен, аларның бүген дә актуаль идеяләрен барлыйк (педагогик коллективларыбызда алар эшчәнлеген актив күтәрик):

**Каюм Насыйри** *«Гыйлем – кодрәтле көч. Әгәр ул әхлаклы зат кулында булса үсешкә, прогресска илтер; әхлаксыз зат кулында тиңе булмаган җимергеч көчкә әверелер»,* дип кисәткән үзенең «Әбүгалисина» әсәре аша.

**Ризаэтдин Фәхреддин** *«...Кадими укыту балаларның гомерләрен генә түгел, остазларныкын да зая итүдер. Әмма үзгәрешләр кертүгә рөхсәт юк. Аз гына тайпылыш та мәдрәсәләргә дәүләт тарафыннан төшерелгән низам (устав) бозу һәм хыянәт дәрәҗәсендәге җинаять булып исәпләнәчәк»*. (Р.Ф.Гарәп лөгате вә аның галимнәре. 95 нче бит).

**Галимҗан Ибраһимов** *«Укылган, ятланган нәрсә тиз онытыла... Гакылыбыз, шөбһәләр, ялгышлар, аңлашылмаулар табып, үзе эзләнсен. Менә бу эзләнү – мөгаллим тарафыннан шәкерт рухына салынырга тиешле иң кыйммәлле, иң җимешле орлыктыр»* («Әдәбият дәресләре» китабында, кадимчеләрне тәнкыйтьләп язган сүзләре; 1916 нчы ел).

**Фатих Әмирхан** *«Вәгазь һәм бер төркем кысынкы низамнар белән генә шәкерткә бер нәрсәне дә тәлкыйн итү (төшендерү) мөмкин түгел генә дип әйтмим, бәлки ул эшләрне бер төрле нәфрәтлендергеч күрсәтергә генә ярыйдыр. Милли рух кертү, милли рухта тәрбия итү шәкерткә «Менә син милли бул, үзең әнсат иткән милләтне сөй, аңа мәхәббәт ит» дию белән генә була торган бер нәрсәмени ул!»* «Милли рух кертү»нең чарасын да әйтеп биргән: *«Бер кавемнең рухын аңлау фәкать аның әдәбияты рухын аңлау, фәкать әдәбияты аркылы гына мөмкиндер».*

**Гаяз Исхакый** *«Әдәбият аркасында без балаларыбызның күңеләрен нечкәртәбез, әдәбият аркасында балаларны уйларга, төшенергә, кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйланырга өйрәтәбез. Әдәбият аркасында балада тәнкыйть хисен үткерлибез, чарлыйбыз, әдәбият аркасында баланың күңелендәге матурлыкка маилне ( тартылуын) куәтләндерәбез»,* ди бөек әдибебез «Мөгаллим әфәнделәр дикъкатенә (укытучылар игътибарына)» мәкаләсендә.

**Мәгърифәтчеләрнең идеяләрен гамәлгә кую ысулларын эзләгән һәм гамәлгә куя алган, ягъни, яңа буын федераль дәүләт стандартлары таләпләрен гамәлгә кую чорында да актуаль хезмәтләр эшләгән галимнәребез:**

**Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов**. *Милләтебез горурлыгы. 1975 нче елларда ук Советлар Союзы дигән держа235ның мәгариф системасын үз артыннан иярткән – үзүсешне тәэмин итү чарасы буларак уку эшчәнлеген проблемалы ситуация тудырып оештыру зарурлыгын исбатлаган һәм гамәлгә куя алган галим.*

**Әхмәт Зәки улы Рәхимов**. *Иҗади эшчәнлек һәм үзүсеш серләрен өйрәнүче, үз фәнни мәктәбен булдыра алган, федераль дәүләт стандартлары таләп иткән «деятельностный подход»ның һәм универсаль гамәлләрнең тәэмин ителү механизмы булган педагогик технологияне инде 1992 нче елда ук тәкъдим иткән татар галиме – психология фәннәре докторы.*

**Альберт Гатуф улы Яхин.** *Әдәбият галиме, федераль дәүләт стандартлары таләпләрен тәэмин итүдә башка милләтләргә дә тәкъдим ителергә лаек әдәбият укыту концепциясе һәм I-XI сыйныфлар өчен укыту-методик комплектлары эшләгән галим, мәгърифәтче.*

Кыскасы, татар милли мәгърифәтчеләре дә һәрчак алгарак карап эшчәнлек алып барган. Димәк, яңа буын федераль дәүләт стандартлары таләпләре татар милли мәгарифе өчен көтелмәгән катлаулылык түгел, ә закончалыклы табигый үсеш күрсәткече.

**1.2. Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары таләп иткән фундаментальлек принцибын тәэмин итү буенча тәкъдим.**

Укытучы укыту-тәрбия процессының нәтиҗәлелеге өчен дәүләт каршында да, социаль заказчылар каршында да беренче чираттагы җаваплы субъект.

Программа һәм укыту-методик комплектларына бәя биргәндә, сайлап алганда моны истә тотарга, зур җаваплылык һәм профессионализм күрсәтергә бурычлы.

Көтелгән нәтиҗәлелекне тәэмин итүдә укытучыга ярдәм итүче факторлар санаулы:

- укыту-методик комплекты (программа, дәреслек, методик кулланма, диагностик пакет);
- танып белү эшчәнлеген оештыруның эчке механизмы – педагогик технология.

**«Әдәбият» укыту предметының сыйфатын тәэмин итүче факторларның берсе буларак А. Г. Яхин төзегән «Әдәбият - 1-4» , «Әдәбият- 5-11» укыту-методик комплекты концепциясе.**

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары таләпләрен эффектив гамәлгә куюда максатка ярашлы «Әдәбият» укыту-методик комплекты буларак Альберт Гатуфович Яхин мирасы маяк була ала.

А. Г. Яхин төзегән «Әдәбият- 1-4» , «Әдәбият- 5-11» укыту-методик комплекты концепциясе белән якыннанрак танышыйк.

Беренче карашка ук, А.Г.Яхинның фәнни институт башкарырга тиешле гигант хезмәт – укыту-методик комплексы эшләгән. Ягъни, программа, I нче сыйныфтан 11 нче сыйныфка кадәр дәреслек, укытучы өчен методик ярдәмлек – компас эшләгән! Әйе, бу формаль күрсәткеч, әмма бусы да татар теле һәм әдәбиятын

укытуда яңалык һәм бердәнбер .

Эчтәлек яңалыгы һәм максатка ярашлыгын (киләчәк көн өчен булу-булмавын) «тикшерик».

Гамәлдәге әдәбият теориясенә нигезләнеп, әдәбият укыту Концепциясе эшләнгән – максаты, принцибы, логикасы программасының аңлатма язуында төгәл һәм аңлаешлы ассызыкланган. Белем нигезе – укучыны фәнни һәм иҗади фикерләргә күнектерү. «Ничек?» классик соравына ачык җавап та бирелә – Әсәргә анализ ясап.

А.Г.Яхин концепциясендә бар да ачык, аңлаешлы:

- өйрәнү объектлары – әсәр (халык авыз иҗаты әсәрләре, әдәби әсәрләр), әдип (шагыйрь, прозаик, драматург) иҗаты, әдәбият тарихы;
- шушы объектларны өйрәнү теориясе – әсәрне уку ысулы, әсәргә анализ, синтез, гомумиләштерү гамәлләре;
- анализ ысуллары – жанрларга, әдип иҗаты бөтенлегенә, әдәбият тарихына анализ. Һәр объект бер үк фикерләү ысулы белән үзләштерелә.

Альберт Гатуфович Яхин концепциясе белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары түбәндәгечә гамәлгә куела:

- федераль дәүләт стандартлары таләпләренең асылы – укытучы һәм укучы арасындагы мөнәсәбәт (деятельностый подход) яңалыгын гамәлгә кую механизмы тәкъдим ителә: укытучы = S укучылар = ss S ↔ s s.

Укучылар белем алырга килә, ә укытучы укучыларның белем алуларын оештырырга тиеш була. А.Г.Яхин үзләштерелергә тиешле һәр төшенчәне хәтер ярдәмендә истә калдырырга тиешле бәйләнешләр күплеге итеп түгел, ә фикер эшчәнлеген оештыру җирлеге буларак бирә.

Укучы үз эшчәнлегенең субъекты булсын өчен, аның танып белү эшчәнлеге мотивлашкан булу зарур, дибез. Ә менә «ничек мотивлаштырырга?» соравы әлегә проблема булды. А.Г. Яхин әлеге проблеманы гади, аңлаешлы чишә. Беренче сыйныф дәреслегенең беренче битләренә игътибар итик: әсәр аша укучы әдәби әсәрдә катнашучылар – әдәби образлар белән таныша башлый. Дәреслек авторы укучы белән әңгәмә кора – һәр төшенчәнең эчтәлеге ачып

бирелә. Аннан соң, фикер йомгагын тәгәрәткәч кенә, бирем бирә.

Шул рәвешле, укучының фикер эшчәнлеге хәрәкәткә китерелә. Дәрестән дәрескә әдәбият предметы буенча теоретик белем киңәя, кулланышка алынып махсус күнекмә формалашуга, камилләшүгә китерә.

Әдәби әсәр текстына кайта-кайта куелган проблемалы сорау һәм биремнәргә җавап эзләгәндә, укучының гомумуку күнекмәләре: аңлы уку тизлеге, фикер эшчәнлеге, фикерен иптәшләренә җиткерә белү күнекмәләре дә формалаша, тотрыклылык ала.

в) белем алуда универсаль гамәлләренең эффектив үзләштерелүе өчен җирлек булдырыла:

- рухи-әхлакый үсешне билгели торган гамәлләр өчен (игътибарлылык, итәгатьлелек, зирәклек, гомумкешелек кыйммәтләренә матур мөнәсәбәт) – татар әдәби мирасы җәүһәрләрен танып белү аша тормыш тәҗрибәсе туплау тәэмин ителә;
- регулятив гамәлләр формалашуы өчен – дәрестән-дәрескә теоретик белем нигезендә уку мәсьәләсен кую, чишү юлларын билгеләү, эффектив булганын сайлап ала алу, чишү, үз эшенә контроль ясый һәм бәя бирә белү күнекмәсе;
- танып белү гамәле – ысул белән коралландыру – әдәби әсәрне укый белү, әдәби жанрга; язучы иҗаты бөтенлегенә, әдәби чорга анализ ясау ысулы төрле белем чыганакларыннан файдалана белү күнекмәсе үсеше һәм эчтәлекнең модельләштерә белү;
- коммуникатив гамәлләре үсеше өчен – укучының әдәби мирасны кабул итү, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә, телдән һәм язмача башкаларга дәлилле җиткерә белү күнекмәләре тотрыклы камилләшә.

Махсус белем һәм күнекмәләрне, белем алуда универсаль гамәлләрне формалаштыруда дәвамчанлык принцибының саклану зарурлыгы һәм «Әдәбият» курсы эчтәлегенең нигезен тәшкил итә торган өлешләр арасында бәйләнеш саклануын (урта звено белән башлангыч звенода, урта звено белән югары сыйныфларда, башлангыч звено белән мәктәпкәчә чорда, татар милли мәгърифәтчелек идеяләре һәм бүгенге заман таләпләре, федераль

дәүләт стандартлары яссылыгында) тәэмин итүгә аеруча әһәмият бирә.

Дәрестән дәрескә, сыйныфтан сыйныфка күчкәндә (димәк, баскычтан баскычка да) белем эчтәлегенең эзлекле үсеше саклана. I–XI сыйныфка кадәр үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр бер системаның аерылгысыз өлешләре буларак эшләнгән.

Белемнең фундаменталь булуы (фәннең милләте юк, димәк теләсә кайсы  уку предметы балаларга фундаменталь – үзгәртергә ярамый торган, теоретик белем һәм күнекмәләр бирергә тиеш) – татар әдәбияты дәресләрендә үзләштергән белем һәм күнекмәләр балага рус әдәбиятын һәм башка милләтләр әдәбиятын үзләштергәндә дә ярдәм итә ала торган белем һәм күнекмә бирелә.

А.Г. Яхин «Әдәбият» укыту  концепциясе бердәм өч максатны эффектив хәл итә:

1. Дидактик максат (нинди теоретик белем формалаштырылга, үзләштерелергә тиешлеге): автор белән укучы (читатель) мөнәсәбәте аша әсәрнең эчтәлеген – темасын, күтәрелгән проблеманы, ул проблема  чишелешенең автор тәкъдим иткән вариантын, әсәрнең идеясен табу.  Татар халык авыз  иҗатын, әдәби әсәрләрне, әдип иҗатын, әдәбият тарихын  бөтенлек  итеп  өйрәнү күнекмәсе формалаштыру.

Башлангычта: әдәби әсәрне укый белү – катнашучыланы табу, аларның сыйфатларын һәм гамәлләрен аерып алу, гамәлләреннән чыгып бәя бирү күнекмәсе формалаштыру.

Урта баскычта: татар халык авыз  иҗатына, әдәби әсәрләргә, әдип иҗатына, әдәбият тарихына анализ ясый белү күнекмәсе, профиль алды әзерлеге.

Югары баскычта: хәзерге заман әдәбиятына анализ ясый белү күнекмәсе, профильле белем бирү.

2.Үстерешле  максат: фәнни, иҗади фикерләү күнекмәсе; моның өчен фикерләүнең  барлык формаларын (чагыштыру, гомумиләштерү, таркату, кабатлау) даими кулланышка кую.  Шул рәвешле игътибарлылык,  зирәклек,  тапкырлык, кызыксынучанлык кебек мөһим, шәхес буларак үсешне күрсәткән сыйфатлар формалаштыру, гамәлләр белән коралландыру.

3.Тәрбияви максат (нәрсәгә, нинди мөнәсәбәт формалашуы): Татар халкының рухи кыйммәтләрен чагылдырган әдәби мирасны (халык авыз иҗаты әсәрләрен һәм әдәби әсәрләрне) үзләштерү, геройларның гамәлләренә, холыкларына бәя бирү, яшәү фәлсәфәләрен өйрәнү, үрнәк яисә гыйбрәт алу аша тормыш тәҗрибәсе туплау. Сәнгать әсәре тудыра алган авторга ихтирам хисләре уяту. Бу максатка ирешү юлы ачык: рухи тәрбия – әсәрләргә анализ ясау нәтиҗәсе. Укыту-методик комплексның эчтәлегендә үгет-нәсихәт юк! Программага яхшы, ягъни, кимендә ике (объектив һәм субъектив яки объектив һәм өстәмә) эчтәлекле әсәрләр генә кертелгән!

Нәтиҗәдә: күп мәдәниятлелек һәм күп теллелек шартларында башкаларның кыйммәтен белеп, танып, ихтирамлы булып үзе булып кала белгән шәхес, милләт вәкиле үсеше өчен җирлек булдырыла.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандарты таләбе – белем бирүдә фундаментальлек принцибының эффектив гамәлгә куелуы өчен җирлек булдырыла. Татар әдәбияты дәресләрендә үзләштерелгән белем күнекмәләр – теләсә кайсы халыкның әдәбиятын үзләштерү ысулы була ала.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә кую чорында яшь белгеч өчен дә, гомер буе үзе сөйләргә, көткән җавабын гына ишетергә күнеккән тәҗрибәле укытучыга да алыштыргысыз ярдәмче, алай гына түгел, әдәбият предметы буенча белем чыганагы булачак.

## 2. «Әдәби уку», «Әдәбият» дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру буенча тәкъдим

Хөрмәтле коллега, белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары һәр предмет эчтәлеген үзләштерү барышында укучыларны универсаль гамәлләр белән коралландыруны таләп итә, дидек. Мәгълүм булганча, белем бирү оешмаларында уку эшчәнлеген оештыруның төп һәм классик формасы – дәрес.

«Дәрес - белем, тәрбия бирү, үстерү бурычларнын хәл итеп, укытучы һәм укучылар катнашында, системалы һәм билгеле бер вакыт аралыгында кулланыла торган укучы эшчәнлеген оештыру формасы. Дәрестә укыту-тәрбия процессының барлык педагогик элементлары катнаша: максат, эчтәлек, чаралар, методлар, оештыру һәм идарә эшчәнлеге, барлык дидактик звенолар» (Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов, Современный урок.М.: Педагогика, 1981).

Нинди предмет укытуыбызга карамастан, дәреснең структур берәмлекләре саклану зарур. Дәрес теориясен искә төшерик.

Һәрбер структур берәмлек, үзе төрләргә бүленә:

- танып белү эшчәнлеген оештыру формалары - индивидуаль, төркемдә (в группе), фронталь;
- чаралар - белем чыганаклары (дәреслек, белешмә сүзлекләр, интернет ресурслары); техник чаралар, күрсәтмә һәм тарату материалы, такта ( 20 нче гасыр яисә 21 нче гасыр тактасы), укучының эш дәфтәре (эш дәфтәре дә кәгазь һәм электрон була ала);
- танып белү эшчәнлеген оештыру методлары *(уку-танып белү процессын оештыру характеры буенча, бу бүленеш авторы М.И.Мәхмүтов):*

1) аңлатмалы - күрсәтмәле; 2) репродуктив; 3) өлешчә эзләнүле; 4) проблемалы ситуация тудыру; 5) тикшерүле.

- танып белү эшчәнлегенең планлаштырылган нәтиҗәлелегенә контроль, бәя, пробелларны бетерү укытучы тарафыннан, класссташлар һәм укучы - үзең тарафыннан (үзконтроль, үзбәя) башкарылырга мөмкин;
- көтелгән нәтиҗәлелек – белем алуда федераль дәүләт

стандартлары таләп иткән махсус белем, күнекмәләр һәм махсус белем күнекмәләрнең тотрыклылыгын, тирәнлеген тәэмин итүче универсаль гамәлләр формалашуы;

- бердәм өч максатны (дидактик, үстерешле, тәрбияви) конкретлаштыруга таләпләр.

Дәрес структур берәмлекләренең югарыда саналган төрләренең эчтәлекләре дә, тәэмин иткән нәтиҗәлелекләре дә төрле. Шуңа күрә укытучы дәрес структурасы берәмлекләре төренең максатка ярашлыларын кулланырга бурычлы һәм хокуклы.

Безнең фикеребезчә, дәрестә танып белү эшчәнлеген оештыруның

- формасы – төркемнәрдә, нигездә;
- методы –тикшерүле, нигездә;
- контроль, бәя, пробелны бетерү – үзконтроль, үзбәя, нигездә .

Искәрмә: бәяләүнең (билге куюның) асыл бурычы - укучы эшчәнлеген бәяләү аша укытучының үз эшен, уку эшчәнлегенең оештырылу сыйфатын контрольдә тоту;

- чаралар – нигездә, белем чыганаклары, такта, укучының эш дәфтәре;
- нәтиҗәлелек - махсус белем күнекмәләр генә түгел, универсаль гамәлләр формалашуы өчен дә җирлек тудырылу.

**«Әдәбият» укыту предметының сыйфатын тәэмин итүче факторларның берсе буларак укучыларның танып белү процессын нәтиҗәле оештырга ярдәм итүче эффектив механизм - педагогик технология.**

Озак еллар алып барылган фәнни эшчәнлек тәҗрибәсе күрсәткәнчә, Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе (Ә.З.Рәхимов.Психодидактика. Уфа: Издат-во «Творчество», 2007) укыту-тәрбия процессының көтелгән нәтиҗәлеген гарантияләүче факторларның берсе – укучыларның танып белү прцессын нәтиҗәле оештырга ярдәм итүче эффектив механизм - педагогик технология.

**Танып белү эшчәнлеге оештырылуны эффектив итә торган дәрес структурасы**

(Академик, психология фәннәре докторы
Әхмәт Зәки улы Рәхимовның иҗади үсеш технолгиясенә
корылган дәрес структурасы)

*Искәрмә:* дәреснең дидактик максаты, ягъни нинди махсус белем ни дәрәҗәдә күнекмәгә әйләнергә тиешлеге генә конкретлаштырыла; ә тәрбияви (45 минут вакыт аралыгында, теге яки бу теоретик белем һәм күнекмәләрнең үзләштерелүен тәэмин итү барышында нәрсәгә, нинди мөнәсәбәт формалаштырырга тиешлеген) һәм үстерешле (нинди фикерләү формалары, ни дәрәҗәдә кулланышка кертелү чикләре ) конкретлаштырылмый, чөнки Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенең эчтәлеге физиология, психология, педагогика, дидактика, философия канӯннарын бер төен итә. Бу исә технология төгәл гамәлдә булганда, һәр дәрестә фикерләүнең барлык формалары һәм төрләре дә кулланышка керүгә, предметның дидактик бурычларын хәл итү барышында укучыларда бик күп кыйммәтләргә (үз-үзенә, классташка, эшчәнлек сыйфатына, укытучыга, вакытка һ.б. бик күп кыйммәтләргә) мөнәсәбәт формалашуын тәэмин итә.

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

Бу этапта башкарылырга тиешле эшчәнлек адымнары:

1. Өй эшләренә анализ. Кайсы өй эшен, ничек эшләгәннәр. Иң яхшы эш кемнеке, ни өчен?

2. Белемнәрне тигезләү - актуальләштерү, ягъни бүгенге теманы үзләштергәндә кулланышка керергә тиешле, инде үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү, барлык балаларны да бер яссылыкка кую, яңа белем, күнекмәләрне үзләштерүгә бер дәрәҗәдә әзер итү .

3. Уку мәсьәләсен - бүгенге дәрестә үзләштерелергә тиешле белем, күнекмәләрне конкретлаштыру ситуациясе тудыру (Уку мәсьәләсе = дидактик максат). Бу – дәреснең бик мөһим мизгеле: белгән белән белмәгәннең чиген ачыклау - мотивлаштыру процессы.

**II.Уку мәсьәләсен (УМ) адымлап чишү этабы.**

1. Уку мәсьәләсен (укытучы проблемалы сорауларга һәм биремнәргә бүлә - УМ = 1,2,3) адымлап чишү оештырыла: һәр би-

рем чишелә→нәтиҗә аерып алына→бергәләп→бер-берсенә→үз-үзләренә сөйләнә→нәтиҗәләр гомумиләштерелә →укытучы критерий бирә→ укучылар үзбәя куя.

Гомумиләштерелгән нәтиҗә ($н_1$ + $н_2$+ $н_3$= Н) УМ нең чишелеше була.

2. Модельләштерү - ысул аерып алу, дәрестә башкарылган эшне кыскача язуда күрсәтү.

**III. Рефлексия, бәя этабы.**

1. Рефлексия - дәрестә узган юлны кире узу. Ягъни

- нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә);
- ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә);
- нинди нәтиҗә ясадык? (Н = $н_1$ + $н_2$+ $н_3$), дигән сорауларга җавап бирү.

2. Дәрестәге эшчәнлеккә үзбәя.

Укытучы критерий бирә, шул нигездә балалар үз-үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийга туры килүен билгелиләр.

Искәрмә:

Универсаль критерий:

Нәрсә эшләргә тиеш идек? Ничек эшләдек? Нинди нәтиҗә ясадык? дигән сорауларга

а) терәк конспекттан, (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып кына сөйләп бирә алса - «3»ле;

б) терәк конспектка күз төшергәләп кенә сөйли алса - «4»ле;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча, сөйли алса - «5»ле.

3. Өйгә эш алу.

Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә:

- репродуктив эшчәнлеккә, ягъни класстагы эшкә охшаш, үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне куллана белү таләп ителгән эш (бу эш мәҗбүри - һәркем эшләргә тиеш);
- конструктив эшчәнлеккә - ярым иҗади, ягъни белем һәм күнекмәлерне аз гына яңа шартка күчерүне таләп иткән эш; бу бирем ихтыярый;
- иҗади эшчәнлеккә, ягъни белем һәм күнекмәлерне яңа җирлектә куалану өчен бирелә; бу эш тә ихтыярый.

**Укучыларның танып белү эшчәнлеге иҗади үсеш технологиясенә корылганда дәрестән дәрескә түбәндәге нәтиҗәлелек тәэмин ителә:**

**1.Махсус белем һәм күнекмәләр тотрыклы формалаша.**

Дәрестән дәрескә әдәбият предметы буенча теоретик белем киңәя, кулланышка алынып махсус күнекмә формалашуга, камилләшүгә китерә.

Әсәр текстына кайта-кайта куелган проблемалы сорау һәм биремнәргә җавап эзләгәндә, укучының гомумуку күнекмәләре: аңлы уку тизлеге, фикер эшчәнлеге, фикерен иптәшләренә җиткерә белү күнекмәләре дә формалаша, тотрыклылык ала.

2. Образлы һәм фәнни фикерләү күнекмәсе тәэмин ителә. Укучы чагыштыру, таркату, гомумиләштерү кебек фикерләү ысулларын даими куллана.

3. Белем алуда универсаль гамәлләрнең тотрыклы формалашуы өчен җирлек булдырыла

4. Игътибарлылыгы (*күңел күзе*), хәтере (*үзләштергән белем күнекмәләре тотрыклылана*) үсә.

5. Белем чыганагы («Әдәби уку», «Әдәбият» дәреслекләре, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», «Татарча-русча сүзлек») белән эш күнекмәсе тотырыклы формалаша.

6. Сәламәтлегенә – физик һәм психологик халәтенә мәктәп тормышы тискәре йогынты ясамый: укучының һәр әгъзасы - баш мие, умыртка баганасы, күзләре, куллары, теле даими хәрәкәттә; укучы тыңлый, ишетә, күрә, уйлый, сөйли, яза һ. б.; киеренкелеккә урын калмый, чөнки ул ялгыз түгел - ул сыйныфташлары, укытучысы, белем чыганаклары (дәреслек, төрле белешмә сүзлекләр, укучының эш дәфтәрендәге язмалары) ярдәмендә белем үзләштерә. Бала кече яшьтән бик кыйммәтле хакыйкатьне танып белү ситуациясенә куела: уңыш һәм уңышсызлык кешенең үзеннән тора.

## 3. Көтелгән нәтиҗәлелекне планлаштыру буенча тәкъдим

### Укытучының эш программасының структурасы:
### Титул бите

Белем бирү оешмасының юридик исеме.

Раслануны дәлилләүче педагогик киңәшмә беркетмәсе (№, дата), гамәлгә куелуны законлаштыра торган боерык (№, дата) һәм директор имзасы, мөһер.

Эш программасының исеме («Әдәбият» уку предметынн-нан эш программасы); кайсы сыйныф өчен, атнага ничә сәгать исәбеннән елга ничә сәгать каралуы.

Төзүчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, квалификация категориясе.

Методик берләшмә карарының килешенүен раслап директор урынбасары имзасы, дата.

Каралуын, анализлануын, кабул ителүен раслап методик берләшмә (МБ) утырышы беркетмәсе (№,дата), МБ җитәкчесе имзасы.

### Аңлатма язуы

Эш программасының нигезе булган Программа, сайлап алынган укыту-методик комплекты күрсәтелә, аларның максатка ярашлыгы дәлилләнә.

Программада тәкъдим ителгән сәгатьләрнең бүленешенә кертелгән үзгәрешләр дәлилләнә.

Үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр ассызыклана.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары таләп иткән нәтиҗәлелек компоненты - белем алуда универсаль гамәлләрнең ничек итеп тәэмин ителәчәге ассызыклана.

**Тематик план.** Аның структур берәмлекләре хокукый акт белән билгеләнмәгән. Тәҗрибә күрсәткәнчә, һәр муниципаль берәмлек аңа үз таләпләрен куя.

Фикер йөртеп карыйк: кайчан эшләнә бу эш программасы?ни өчен эшләнә? Нәрсә ул – тематик план?

Фикер үстерүне соңгы сорауга җаваптан башлыйк: Эш программасы төзү – ул укытучының сентябрьдән майга кадәр узылачак юлны теоретик узуы. Максат бер – укытуның көтелгән сый-

фатын тәэмин итү өчен мөмкинлекләрне барлау.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары укытучыдан һәр укучыны үзүсешкә алып бара торган танып белү эшчәнлеге оештыруын таләп итә. Димәк, укытучының эшчәнлеге бик эффектив булу зарурлыгы туа. Ягъни аның вакыты да, сәламәтлеге дә (күз нурлары) юк-барга, белем сыйфатына, профессиональ компетентлык үсешенә бер катнашы да булмаган мизгелләргә сарыф ителергә тиеш булмый булып чыга.

Укытучының һәр эше максатка ярашлы, эффектив булсын, дигән теләк белән тематик планның без гадәтләнмәгән структур берәмлекләрен тәкъдим итәбез.

## Тематик план

| Структур берәмлекләр | Эчтәлек |
|---|---|
| Бүлек темасы | I бүлек. Сәнгать теле |
| Бу бүлеккә мин биргән сәгать саны | 48 сәгать |
| Алдагы баскычта үзләштерелгән махсус белем һәм күнекмәләрне кулланышка кертү | Әдәби әсәр, әдәби әсәрне уку күнекмәсе, әсәрдә катнашучылар (образлар, автор һәм укучы), катнашучыларның сыйфатлары, әсәрнең өлешләре; өлешләргә бүлүче чаралар. Дәреслек, текст белән эшләү; сайлап уку, сәнгатьле уку, үз фикереңне дәлилли белү, бәйләнешле, эзлекле итеп сөйләү һәм язу; кыскартып сөйләү күнекмәләрен үстерү. Гомумиләштерү, таркату, кабатлау, чагыштыру кебек фәнни фикерләү формаларын куллану күнекмәләрен үстерү .<br>Иҗади күзаллау күнекмәләрен үстерү.<br>Күмәк танып белү эшчәнлегендә актив катнашу, бәяли белү күнекмәсен камилләштерү.Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү, иптәшләреңнең җавабын тыңлый белү күнекмәсен үстерү |
| Бу сыйныфта үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | Әдәбият дәресләренең максаты.<br>Сәнгать теле алымнарын (каршылык, чагыштыру, сыйфат дәрәҗәсе, кабатлау, метафора) һәм аларның төрләрен, үзенчәлекләрен үзләштерү. Мәкальләрне әйтемнәрдән аера белү күнекмәләрен үстерү. «Хис », «хис дәрәҗәсе», «хис сәбәбе », «юану» төшенчәләрен; «миф», «бәет», «нәсер», «халык җыры», жанрларын танып белү |
| Кулланылган әсәрләр | Юмористик һәм лирик шигырьләр (Ш.Галиев, Г.Тукай, Н.Думави,Б.Рәхмәт, Ф.Сафин, М.Әгъләмов, М.Җәлил); проза әсәрләре (И.Низамов, Ф.Әмирхан хикәяләре; М.Әмир,Г.Ибраһимов, М.Галәү әсәрләреннән өзекләр).Халык авыз иҗаты әсәрләре (әкиятләр, җырлар, бәетләр мәсәлләр, табышмаклар, әйтемнәр, мәкальләр, мәзәкләр, мәзәкчәләр) |

| | |
|---|---|
| ТР дәүләт телләрендә үзләштерелергә тиешле төшенчәләр | Сәнгать теле – художественное слово; Сәнгать алымы – художественное средство; Халык авыз иҗаты - народное творчество; мәкаль- пословица; әкият -сказка; әйтем - поговорка; табышмак -загадка; бәет - былина, историческая песня; мөнәҗәт - псалом; мәзәк - юмореска, анекдот; мәсәл - басня; хикәя - рассказ; вакыйга – событие, хис - чувство |
| Өстәмә белем чыганаклары | «Әдәбият белеме» терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан, 2007. «Татар мифологиясе». – Казан, 2008.<br>«Татарча-русча фразеологик сүзлек». – Казан, 2001.<br>Толковый словарь русского языка. С.И.Ожегов. М.1998. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.<br>Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел. |
| Дәрестән тыш уку | ------------------------- |
| Иҗади эш | «Төш» дигән исемле әкият язу(9-дәрес). |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | Ирекле темага әкият язу (27-дәрес).<br>Сочинение(43-дәрес Ф.Әмирханның «Нәҗип » хикәясе буенча)«Үкенү» |
| Контроль кисем, (* ) контроль эшләр(**) | 19-дәрес (* ), бирелгән хикәяне әйтемнәр белән баетып язу.<br>20-дәрес, (* ) бирелгән текстан мәкальләрне генә аерып алып язарга.<br>33-дәрес (* )Халык җырларында хис өлешләрен билгеләү.<br>47-дәрес (**) Максат: бәя бирү һәм сәнгать алымнарын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү |

Тематик план эчтәлегеннән күренгәнчә, укытучы бик зур, әмма бик мөһим эш башкара: дәвамчанлык принцибын гамәлгә кую максатында башлангыч баскыч программасын кабат өйрәнә. Үз сыйныфы программасын җентекләп үзләштерү, социаль заказларның ( ТР дәүләт телләрен үзләштерү) үтәү юнәлешендә үз бурычын тәэмин итүне планлаштыра. Кулланылышка керергә тиешле белем чыганакларын барлый: үз китапханәсендә, мәктәп китапханәсендә һ.б. Программа таләп иткән эш төрләрен, аларның үзенчәлеген, оештыру характерын үз укучыларына килештереп, үз мөмкинлекләрен исәпкә алып планлаштыра. Аннан икенче, өченче һ. Б. бүлекләр шулай ук планлаштырыла.

Августның соңгы көннәрендә беренче бүлек дәресләргә таркатыла.

| Т\ с | Беренче бүлекнең дәресләргә бүленеше (дәрес темалары) | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Сәнгать теле | |
| 2 | Сәнгать алымнары: чагыштыру, каршылык | |
| 3 | Сыйфат дәрәҗәсе,кабатлау, мәгънә | |
| 4 | Шәүкәт Галиевнең «Кем белә?» «Чабалар», «Атлап чыктым Иделне» шигырьләрендә чагыштыру юлы белән бәя бирү | |
| 5 | Г. Тукайның «Баскыч» шигырендә чагыштыру аша бәя бирү | |
| 6 | «Бәхетле», «Балыкчы» мәзәкләрендә чагыштыру юлы белән бәя бирү | |
| 7 | «Хәйләкәр этәч» әкиятендә каршылык аша бәя бирү | |
| 8 | «Төлке белән торна»,»Әләкче» әкиятләрендә каршылык аша бәя бирү | |
| 9 | Б.с.үстерү.Иҗат эше: әкиятнең дәвамын язу | |
| 10 | Ябалак», «Акыллы килен» әкиятләрендә вакыйга үзгәрү тудырган каршылык | |
| 11 | Г. Тукайның «Күгәрчен» шигырендә каршылык (күнегү) | |
| 12 | Г. Тукайның «Таз» шигыренең сюжеты | |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Г. Тукайның «Таз» шигырендә вакыйга үзгәрү тудырган каршылык | |
| 14 | Ш. Галиевнең «Надан», З. Бәширинең «Яхшылык» шигырьләрендә мәгънә | |
| 15 | Дәрдемәнднең «Богдай» хикәясендә мәгънә (күнегү) | |
| 16 | И.Низамовның «Теш үтмәгәч» хикәясендә мәгънә (158 нче бит) | |
| 17 | Әйтемнәрдә мәгънә | |
| 18 | Б.с. үстерү. Мөст.эш. Хикәяне әйтемнәр белән баетып язу | |
| 19 | Мәкальләрдә  мәгънә. | |
| 20 | Б.с. үстерү. Мөстәкыйль эш. Мәкальләрне генә аерып язу | |
| 21 | «Аю белән бабай» әкиятендә каршылык (күнегү) | |
| 22 | «Төшеңне сөйлисеңме?» әкиятендә каршылык.(күнегү) | |
| 23 | Мәзәкләрдә каршылык | |
| 24 | .Мәзәкләрдә каршылык  (күнегү) | |
| 25 | Ш.Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигырендә каршылык (күнегү) | |
| 26 | Б.с.үстерү. Иҗат эше. Ирекле темага әкият язу | |
| 27 | М.Җәлилнең «Су төбендә» шиг-дә каршылык (күнегү) | |
| 28 | Сыйфат дәрәҗәсе төре буларак халык җырлары | |
| 29 | Хиснең сәбәбенә багышланган дүртьюллыклар | |
| 30 | Юануга багышланган дүртьюллыклар | |
| 31 | Халык җырларында хиснең дәрәҗәсе, сәбәбе, юану өлешләре | |
| 32 | Б.с. үстерү.Мөстәкыйль эш: халык җырларында хис өлешләрен билгеләү | |
| 33 | Бәетләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре» (170 нче бит) | |
| 34 | Мәзәкчәләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре | |
| 35 | Шигырьләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре | |
| 36 | Әкиятләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре  (191 нче бит) | |

| | | |
|---|---|---|
| 37 | Г. Тукайның «Бәйрәм бүген» шигырендә кабатлау алымы | |
| 38 | Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә кабатлау алымы (күнегү) | |
| 39 | Б.с.ү. Контроль эш №1: сәнгать алымнары | |
| 40 | Табышмаклар. Аларның төзелеше | |
| 41 | Метафора. Ф. Сафинның «Очты-китте яшелең» шигырендә метафора | |
| 42 | Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясе сюжеты | |
| 44 | Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясендә метафора | |
| 45 | Б.с. үстерү.Сочинение «Нәҗипнең кичерешләре» яки «Үкенү» | |
| 46 | М. Әгъләмовның «Тургай» шиг-дә метафора (күнегү) | |
| 47 | Р.Фәйзуллинның «Таң», М. Гафуриның «Гомерем йомгагы» (174 нче бит) шигырьләрендә метафора (күнегү) | |
| 48 | М.Җәлилнең «Чишмә җыры» шигырендә метафора (176 нчы бит, күнегү) | |

**1. Төп гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларында кулланылган төшенчәләрнең рус һәм татар телләрендә аңлатмалы сүзлеге.**

| Рус телендә | Татар телендә |
|---|---|
| миссия федеральных государственных образовательных стандартов: выявление и согласование индивидуальных, общественных и государственных потребностей в общем образовании | Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларының миссиясе: гомуми белем бирүдә шәхси, иҗтимагый һәм дәүләти ихтыяҗларны ачыклау һәм килештерү |
| С введением ФГОС в системе общего образования ожидаются следующие изменения: образовательные цели; качество образования; учебный план; содержание учебных программ и программ внеурочной деятельности; характер организации образовательного процесса); ресурсное обеспечение); система оценки качества образования | Белем бирүдә федераль дәүләт стандартлары гамәлгә куелу белән гомуми белем системасында мондый үзгәрешләр булачак: тәгълим-тәрбия процессының максатлары; белем сыйфаты; уку планы; уку һәм дәрестән тыш эшчәнлек программалары эчтәлеге; тәгълим-тәрбия процессын оештыру характеры; ресурслар белән тәэмин ителеш; белем сыйфатын бәяләү системасы |
| «Деятельность » – это это процесс преобразования реальной действительности для достижения намеченной цели и удовлетворения возникшей потребности | «Эшчәнлек» – куелган максатка ирешү һәм барлыкка килгән ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен реаль чынбарлыкны үзгәртү процессы |
| «Действие » – это это единичный акт преобразования действительности | «Гамәл » – чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән бер адым |
| «Самоконтроль » - это процесс соотнесения промежуточных или конечного результатов с промежуточными или конечной целями деятельности | «Үзконтроль» – агымдагы һәм соңгы нәтиҗәләрнен эшчәнлекнең агымдагы һәм соңгы максатлары белән чагыштыру процессы |

| | |
|---|---|
| «Самооценка»- это процесс сопоставления результата деятельности с ее целью, можно установить, на сколько результат соответствует | «Үзбәя» –эшчәнлекнең нәтиҗәсен максат белән чагыштыру һәм аның ни дәрәҗәдә куелган максатка туры килүен ачыклау |
| цели и осуществляется по полноте состава и качеству реализованных действий | |
| «Универсальные учебные действия» – это умение учиться, т. е. способность субъекта к саморазвитию и самосовершенствованию путем сознательного и активного присвоения нового социального опыт | «Белем алуда универсаль гамәлләр» – белем эстәүгә сәләтлелек, ягъни субъектның аңлы һәм актив рәвештә яңа социаль тәҗрибә үзләштерү аша үзүсешкә, үзлектән камилләшүгә сәләтле булуы |
| «Регулятивные действия » – это умение в любой деятельности прежде выявлять проблему, определить пути решения, выбрать наиболее эффективных способов решения, самостоятельно решить выявленную проблему, рефлексировать, дать самооценку и самостоятельно определить резерва усовершенствования решения этой проблемы | «Регулятив гамәлләр » – теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала , аның чишелеш юлларын билгели, иң эффектив чишелеш юлын аерып ала, аерып алынган проблеманы мөстәкыйль хәл итә, рефлексия ясый, үз эшенә адекват бәя бирә һәм әлеге проблема чишелешен тагын да эффектив итү өчен үзенә нәрсә эшләү, нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын ачыклый белү |
| « Коммуникативные действия» – это умение слушать и слышать, услышенного сравнивать собственным, в соответствии с грамматическими и синтаксическими нормами родного языка и русского языка в диалоге и в монологе высказывать и аргументировать свое мнение; участвовать в коллективном обсуждении проблем, умение интегрироваться в группу сверстников и строить продуктивное взаимодействие со сверстниками и взрослыми | «Коммуникатив гамәлләр » – тыңлый, ишетә, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыра, туган теленең һәм рус теленең грамматик, синтаксик нормаларына туры китереп, дәлилле итеп үз фикерен монологта һәм диалогта башкаларга җиткерә белү; килеп чыккан проблемаларны коллективта уртага салып хәл ит белү; яшьтәшләре белән төркемгә берләшә, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән продуктив уртак гамәл оештыра алу |

| | |
|---|---|
| «Познавательные действия » – это – умение преобразование изучаемого объекта из чувственной формы в модель, где выделяются существенные характеристики объекта и преобразование модели с целью выявления общих законов, | «Танып белү гамәлләре» – өйрәнелә торган объектны хис формасыннан объектка хас төп үзенчәлекләрне аерып күрсәтә торган модельгә әйләндерә һәм үзләштерелә торган предмет өлкәсен билгели торган гомуми |
| определяющих данную предметную область ;<br>–выделение универсальных логических действий: анализ объектов с целью выделения существенных, несущественных признаков;<br>– синтез как составление целого из частей, в том числе самостоятельное достраивание, восполнение недостающих компонентов;<br>–выбор оснований и критериев для сравнения, классификации объектов;<br>– подведение под понятия, выведение следствий;<br>–установление причинно-следственных связей, построение логической цепи рассуждений, доказательство;<br>– выдвижение гипотез и их обоснование | закончалыкны ачыклау максатында модельне үзгәртә белү;<br>– универсаль логик гамәлләрне аерып ала белү: объектка хас мөһим һәм бик үк мөһим булмаган билгеләрне аерып алу максаты белән объектка анализ ясый белү;<br>– өлешләрдән бөтен хасил итү буларак синтез ясый белү, шул исәптән, мөстәкыйль рәвештә җитешмәгән өлешләрне таба, төзеп (тулыландырып) бетерә белү;<br>– өйрәнү объектларын чагыштыру, классификацияләү өчен нигез һәм критерий сайлый белү;<br>– килеп чыккан нәтиҗәләрне төшенчә итеп формалаштыру;<br>– сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау һәм фикер үстерелешенең, дәлилләүнең логик чылбырын төзү;<br>– гипотеза тәкъдим итү һәм аны дәлилләү |
| «Личностные действия » – это готовность к жизненному и личностному самоопределению, знание моральных норм, умение выделить нравственный аспект поведения и соотносить поступки и события с принятыми этическими принципами, а также ориентации в социальных ролях и межличностных отношениях | «Рухи-әхлакый үсешне күрсәтүче гамәлләр » – тормышта үз урыныңны табарга әзерлек, мораль нормаларны белү, үз-үзеңне тотуның әхлакый асылын аера белү һәм гамәлләреңне кабул ителгән этик принципларга туры китерү , шәхесара мөнәсәбәтләрдә һәм социаль рольләрдә ориентлаша белү |

## 2. Иҗади үсеш технологиясенә корылган дәрес эшкәртмәсе

**Беренче дәрес**

**Дидактик максат:** әсәр белән эш ысулын актуальләштерү.

Кулланылган әсәр: **Габдулла Тукай. «Эш».**

Чыганаклар: **Дәреслек. 2 сыйныфтагы эш дәфтәрләре.**

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

**1. Актуальләштерү** (алда үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү).

Төркемнәрдә киңәшеп үткән елгы эш дәфтәрләрендәге язмаларны файдаланып, искә төшерегез:

- Әдәби уку дәресләрендә ни белән шөгыльләнәбез?
- Көтелгән җавап: Әсәрләр укыйбыз.
- Әсәр уку ничек була?

**Көтелгән җавап:**

Әсәрнең эчтәлеген табу – әдәби уку була. Әсәр эчтәлегенә сюжет, тема, авторның укучыга әйткән фикере керә.

**2. Уку мәсьәләсен куюю ситуациясе тудыру.**

- Бүгенге дәрестә безгә Габдулла Тукайның «Эш» әсәрен өйрәнергә кирәк. Киңәшегез әле, эшне ничек оештырырбыз икән?

Көтелгән җавап:

- Әсәрне гөжләп тиз һәм аңлап укырбыз.
- Әсәрнең исеменә игътибар итәрбез.
- Авторны истә калдырырбыз.
- Аңлашылмаган сүзләрне ачыкларбыз (Ничек? Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән; Татарча-русча сүзлектән файдаланып, яисә синонимнарын табып, бер-беребезнең аңлатмасын тыңлап).
- Персонажларны табарбыз. Аларның гамәлләренә бәя бирербез.
- Сюжетын үз сүзләребез белән сөйләрбез.
- Әсәрнең ни турында булуын - темасын ачыкларбыз.
- Авторның укучысына җиткерергә теләгән фикерен табарбыз.

**Искәрмә:** Әсәрне өйрәнү ысулы тактага язып куела. Балалар хор белән, бер-берсенә, үз-үзләренә ысулны кабатлыйлар.

**Үзбәя өчен критерий бирелә:**

- Әсәрне өйрәнү ысулын терәк конспекттан (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып та сөйләп бирә алмасагыз - «2»ле;
- терәк конспекттан файдаланып сөйләп бирә алсагыз - «3»ле;
- терәк конспектка бераз гына караклап сөйли алсагыз - «4»ле;
- терәк конспекттан файдаланмыйча, сөйли алсагыз - «5»ле.

(Вакыт бирелә. Шул рәвешле үз эшчәнлекләренә адекват бәя кую күнекмәсе искә төшерелә. *Кемнәр үзен «2»легә бәяләде? Кем «3»легә?* дип, актуальләштерү адымының оештырылу дәрәҗәсе ачыклана. Ягъни балаларның үзбәясе аша укытучы үз эшчәнлегенә бәя ала).

**II.Уку мәсьәләсен чишү (УМ) этабы.**

1.Габдулла Тукайның «Эш» әсәрен укыйбыз. Катнашучыларны табабыз, аларның эшләрен үз сүзләребез белән сөйләп бирергә әзерләнәбез.

Көтелгән эш һәм җавап: Гөжләп укыйлар.

Сүзлек эше оештырыла: тәңре – Аллаһы Тәгалә, тынарсың – ял итәрсең, җомга көн – безнең әби-бабаларыбыз җомга көнне ял иткәннәр, ә безнең заманда ял көне - якшәмбе; кояш күк – кояш кебек, ялтырарсың – ерактан күренерсең, сине ихтирам итәрләр.

Катнашучыларны табалар (тактада һәм дәфтәрләрдә түбәндәге схема языла – эшчәнлек эчтәлеге модельләштерелә):




Катнашучыларның гамәлләре:

Сабый. Тыңлап кына тора.

Кояш. Бик иртә тора, таң аттыра, көн буе күктә йөзә, җир өстен яктырта, кичен тау артына китеп ял итә, җир шарын – кешеләрне дә ял иттерә.

Автор. Кояшныңниләр эшләвен Автор сөйли. Автор сабыйга аңлата: Аллаһы Тәгалә көнне эшләр өчен, төнне йокы өчен биргән. Шуңа күрә иртә торгач та эшеңә кереш. Синең эшең уку һәм язу. Атна буе тырышып укы, яз. Ял көне генә ял итәргә гадәтлән, ди.

Автор әсәрдә катнашучы сабыйга әйткән булып безгә – укучысына киңәш бирә: әгәр син кояштан үрнәк алсаң, үскәч тә кояш кебек кешеләргә файда китерә торган эшләр эшләсәң, сине дә кояшны яраткан кебек яратырлар, хөрмәт итәрләр. Моның өчен кечкенәдән тырышып укырга кирәк, ди.


Без. Авторның киңәшен рәхмәт әйтеп кабул итәбез.

2. Әсәр нәрсә турында булды?

Күтелгән эшчәнлек һәм җавап:

Эш, үзеңә һәм кешеләргә файда китерә торган эш турында. Чөнки әсәрнең исеме дә «эш». Сюжетта персонажларның файдалы эше турында сүз бара. Сабыйның файдалы эше - тырышып белем алу. Кояшның эше - көн буе җир шарын яктырту, аннары, төн тудырып, кешеләрне ял иттерү.

**3. Модельләштерү** (дәвам итәбез)




**Үзбәя өчен критерий бирелә:**

Габдулла Тукайның «Эш» әсәре эчтәлеген

а) терәк конспекттан (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып сөйләп бирә алсагыз - «3»ле;

б) терәк конспектка күз салгалап сөйли алсагыз - «4»ле;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча сөйли алсагыз - «5»ле.

**III. Рефлексия, бәя этабы.**

**1.Рефлексия.**

- Нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә);

Көтелгән җавап. Габдулла Тукайның «Эш » әсәрен өйрәнергә тиеш идек.

-Ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә);

Көтелгән җавап:

— әсәрне гөжләп һәм аңлап укыдык;

— аңлашылмаган сүзләрне «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән карадык;

— катнашучыларны таптык;

— укыганны үз сүзләребез белән сөйләдек.

**2. Дәрестәге эшчәнлеккә үзбәя.**

Үзбәя өчен критерий бирелә:

- Габдулла Тукайның «Эш » әсәре катнашучылары турында

- терәк конспекттан (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып та сөйләп бирә алмасагыз - «2»ле;
- терәк конспекттан файдаланып сөйләп бирә алсагыз - «3»ле;
- терәк конспектка күз салгалап сөйли алсагыз - «4»ле;
- терәк конспекттан файдаланмыйча, сөйли алсагыз - «5»ле.

(Вакыт бирелә. *Кемнәр үзен «2»легә бәяләде? Кем «3»легә?* дип, дәрестә оештырылган танып белү эшчәнлегенең сыйфаты ачыклана)

Укытучы критерий нигездә балалар үз-үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийга туры килүен билгелиләр.

3. Өйгә эш алу.

Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә:

1.Репродуктив эшчәнлеккә. Г.Тукайның «Эш» әсәре эчтәлеген гаиләдә аңлатырга.

2. Конструктив эшчәнлеккә.

Түбәндәге юлларны ятларга, сәнгатьле укырга әзерләнергә:

Күр ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буена яктыра.
Соңрак, арган төсле ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата..

3. Иҗади эшчәнлеккә.

Кояшның берәр гамәлен чагылдырган рәсем ясарга

*Искәрмә:*

1. Рәсемнәрне А4 форматындагы битләргә ясарга тәкъдим итегез. Алдагы дәрестә иң яхшы иҗади эшләр билгеләнгәч, Сез аларны җыеп алырсыз. Сыйныф кабинетында күргәзмә оештырырсыз. Дәрестән-дәрескә шундый эшләр җыелганнан соң, аларны китап итеп төпләтерсез (типографияләрдә эшләтеп алырсыз). Ул «китап»ны ата-аналарга күрсәтерсез. Ата-аналар үз балаларын башкалар фонында күрерләр, нәтиҗә ясарлар. Бу эшләрне ничек оештыруыгыз турында сөйләрсез.Үгет-нәсихәтсез генә ата-аналарның мәктәп тормышына мөнәсәбәтен үзгәрерсез. Аннан соң «китап»ны мәктәп китапханәсенә бирерсез. Шул рәвешле иҗади эшчәнлек мотивлаштырылыр, иҗат эшенең кыйммәтле кыйммәт булуын таныпбелү оештырылыр.

**Икенче дәрес**

**Дидактик максат:** Өй эшләренә анализ күнекмәләрен үстерү.

1.Өй эшләренә анализ актуальләштерү алымы белән үрелеп бара.

- Төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез: мәҗбүри өй эшен кем ничек оештырган.

(Вакыт бирелә).

Күтелгән эш, җавап: (мисал өчен, бер төркем җавабы)

Без барыбыз да Г. Тукайның «Эш» әсәре эчәлеген гаиләдә сөйләп аңлаттык. Гөлназны әбисе аркасыннан сөйгән. Ниязга әтисе «егет икәнсең улым!» – дигән.

- Ярым иҗади эш - Г. Тукайның «Эш» әсәреннән бирелгән юлларны ятларга, сәнгатьле укырга әзерләнергә иде. Исегезгә төшерегез, «сәнгатьле уку» ничек була?

(Вакыт бирелә. Төркемнәрдә киңәшеп җавап әзерлиләр.)

Көтелгән җавап: Сәнгатьле уку - персонажны күз алдына китереп, аның кебек сөйләү. Сөйләмебездә персонажга мөнәсәбәтебез чагылырга тиеш.

Иң яхшы башкаручыны аерып алырга, ни өчен «иң яхшы» эш булуын аңлатып, сыйныфка тәкъдим итәргә әзерләнергә.

Һәр төркемнән «иң яхшы сәнгатьле укучы» сыйныф алдын-

да чыгыш ясар алдыннан мондый сөйләшү оештырыла:

- Бу юллар кайсы катнашучының сүзләре? Сез аны ничек күз алдына китерәсез?

Көтелгән җавап: Автор сүзләре. Ул бик ягымлы тавышлы. Зур күзләре белән укучысына карап, куллары белән кояшка күрсәтеп, кояш башкарган эшләрне саный кебек. Аның сүзләрендә мактау да, соклану да чагыла.

-Портреты торсын әле дәресебездә, дип Габдулла Тукайның зур портреты эленә. *Хөрмәтле коллега, бөек Тукайны төрле елларда төрлечә сурәтләгәннәр. Сез исә балалар күңеленә матур булып, шигыре аша күз алдына китерелгәнчә сурәтләнгән портретын табарга тырышыгыз. Шул рәвешле әсәрләреннән әсәрләренә без бөек Тукайның бөеклеген танып белербез. Иҗаты аша тирән ихтирам һәм горурлык хисләре формалашуы өчен җирлек тудырырбыз.*

**Бергәләп критерий төзелә:**

- текстны төгәл ятлаган;
- тавышында күзәтүчәнлек, мәрхәмәтлелек, ягымлылык чагыла;
- йөз һәм кул хәрәкәтләре сүзләрнең мәгънәсен тулыландырып тора;
- тавыш тибрәнеше белән авторга ихтирамын белдерә алды.

«Сыйныфның иң яхшы сәнгатьле укучы» сайлап алына.

Иҗади эшчәнлеккә Кояшның берәр гамәлен чагылдырган рәсем ясарга иде. Иң яхшы башкаручыны аерып алырга, ни өчен «иң яхшы» эш булуын аңлатып, сыйныфка тәкъдим итәргә әзерләнергә.

(Вакыт бирелә. Төркемнәрдә киңәшеп «иң яхшы» эшне сайлыйлар.)

Көтелгән бәя мондый була ала: Безнең төркемдә иҗади эшне Илнар белән Алсу эшләгән. Эшләр икесе дә яхшы. Илнарның эшен сыйныфка тәкъдим итәргә булдык. Ул кояшның тау артына китеп барган чагын сурәтләгән. Чыннан да кояш арган, йокыга китәргә әзер төсле. Күк йөзен дә кояш баюны хәтерләтә. Буяуларны дөрес сайлаган. Альбом битен тутырып эшләгән.

Шул рәвешле Г. Тукайның «Эш» әсәре буенча иң яхшы рәсемнәр сайлап алына. Кабинетта күргәзмә оештырыла.

## 3. «Әдәбият» предметы буенча эш программасы төзегәндә файдалану өчен

Аңлатма язуы

**Программа түбәндәге хокукый-норматив документларга нигезләнә:**

*1. «Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон* - Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 № 273-ФЗ.

2.Гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары концепциясе – Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования: / под ред.А.М.Кондакова, А.М.Кузнецова – М.: Просвещение, 2009.

3.Гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше концепциясе- Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В.В.Козлова, А.М.Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.

4.Россия Федерациясе гражданины шәхесенең рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү концепциясе - Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина Российской Федерации: / под ред.А.Я.Данилюк, А.М.Кондаков. – М.: Просвещение, 2009.

5.Гомуми башлангыч белем бирүдә өлге программа эчтәлеге (М.: Просвещение, 2009, 2010).

6.Гомуми төп белем бирүдә өлге программа эчтәлеге. Әдәбият- Литература (М.Просвещение, 2010, 2011).

7. «Әдәби уку – Литературное чтение» уку предметы буенча гомуми башлангыч белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәлелеге.

8. Муниципаль белем оешмасы «Бәркәтә урта мәктәбе» нең үсеш программасы (мисал өчен).

**Әдәби уку буенча эшче программа түбәндәге максатларны гамәлгә куюга юнәлтелә:**

**1.Дидактик максат** (*нинди теоретик белем формалаштырылырга, үзләштерелергә тиешлеге):* Автор белән Укучы *(читатель)* мөнәсәбәте аша әсәрнең эчтәлеген – *темасын, күтәрелгән проблеманы, ул проблема чишелешенең автор тәкъдим иткән вариантын, әсәрнең идеясен* табу һәм төрле жанрны *( табышмак, мәкаль, әйтем, мәзәк, әкият, шигырь, мәсәл, хикәя)* тану, шул җирлектә халык авыз иҗаты әсәрләрен һәм әдәби әсәрне, әдип иҗатын, әдәбият тарихын бер бөтен итеп өйрәнү өчен тотрыклы нигез – автоматлашкан әдәби уку күнекмәсе формалаштыру .

**2.Үстерешле максат:** фәнни, иҗади фикерләү күнекмәсенең камил үсешен тәэмин итү. Моның өчен теоретик белемне фикерләүнең барлык формалары *(чагыштыру, гомумиләштерү, таркату, кабатлау)* белән янәшә даими кулланышка кую. Шул рәвешле игътибарлылык, зирәклек, тапкырлык, кебек шәхеснең интеллектуаль һәм гаделлек, сабырлык кебек әхлакый үсеш дәрәҗәсен билгели торган, шәхес буларак танытучы мөһим сыйфатлар формалаштыру.

**3.Тәрбияви максат** *(нәрсәгә, нинди мөнәсәбәт формалашуы*):

- кече яшьтәге укучыда әдәби китаплар уку, олы әдәби мираска тартылу ихтыяҗы уяту;
- татар, рус, Идел буе халыклары, дөнья халыклары әдәбияты үрнәкләрендә, төрле халыкның рухи кыйммәтләрен чагылдырган халык авыз иҗаты әсәрләре һәм әдәби әсәрләр – геройларның гамәлләренә, холыкларына бәя бирү, яшәү фәлсәфәләрен өйрәнү, үрнәк яисә гыйбрәт алу аша тормыш тәҗрибәсе туплау;
- сәнгать әсәре тудыра алган авторларга, димәк, халык авыз иҗатын тудырган төрле милләт халкына да, ихтирам хисләре уяту.

Нәтиҗәдә: Россия Федерациясе гражданины – *күп мәдәниятлылык һәм күп теллелек шартларында башкаларның кыйммәтен белеп, танып, ихтирамлы булып үзе булып кала белгән шәхес, милләт вәкиле* үсеше өчен җирлек булдыру.

## «Әдәби уку» (« Татар әдәбияты») курсына гомуми характеристика

**Программа эчтәлеген тәэмин итүдә кулланышка куелырга тиешле әсәрләргә гомуми таләпләр.**

- Әсәрләрнең жанр ягыннан күптөрле булу зарурлыгы: табышмак, мәкаль, әйтемнәр, мәзәк, әкият кебек татар һәм Идел буе халыкларының халык авыз иҗаты әсәрләре һәм татар, Россия Федерациясе, чит ил классикларының хикәя, шигырь, мәсәл, әкият кебек әдәби әсәрләре урын алу.
- Югары әхлакый кыйммәтләрне – гомумкешелек кыйммәтләрен сыйдырган әсәрләр генә кулланышка куелу зарурлыгы.

**Нәтиҗәлелекне тәэмин итү принциплары**

- Белем бирүдә фундаментальлек принцибы.

Әдәби уку дәресләрендә үзләштергән белем һәм күнекмәләрнең балага рус әдәбиятын һәм башка милләтләр әдәбиятын үзләштергәндә дә ярдәм итә ала торган булу зарурлыгы. *(Фәннең милләте юк, димәк теләсә кайсы уку предметы балаларга фундаменталь – үзгәртергә ярамый торган, теоретик белем һәм күнекмәләр бирергә тиеш).*

- Аңлаешлылык (доступность) принцибы.

Кече яшьтәге укучы баланың нигез белемнәренә таянып, проблемалар, каршылыклар аша җиңеп чыгарлык, көче җитәрлек әсәрләрнең кулланышка куелуы.

- Мотивлылык принцибы.

Балаларның тормыш тәҗрибәләре, кызыксыну даирәләре белән тәңгәл килерлек, гыйбрәт яисә үрнәк алып тормыш тәҗрибәләрен баетырлык әсәрләрнең генә кулланышка куелуы. Танып белү процессының психологик иркенлек шартларында оештырылу зарурлыгы.

- Күп мәдәни нигезлелек (поликультуралылык) принцибы.

Гомумкешелек кыйммәтләренә, сәнгать әсәре тудыра алган авторга (төрле милләт халкына да) ихтирам һәм кызыксыну хисләре уяну өчен; программа таләп иткән төп төшенчәләрнең татар һәм рус телләрендә үзләштерелүе өчен җирлек тудырылу.

• Системалы эшчәнлек оештырылу ( системно- деятельностный подход) принцибы.

Программа таләп иткән эчтәлекне гадидән катлаулыга принцибы нигезендә бер бөтен буларак үзләштерелүе тәэмин ителү.

• Дәвамчанлык припцибы.

Темалар, бүлекләрләрнең, сыйныфара материалның берсенберсе тулыландырып килүе, үзара бәйләнештә булып бер бөтен тәэмин итүе. Эшче программаның «Татар әдәбиятын I-XI сыйныфларда укыту концепциясе»нә корылган федераль исемлеккә кертелгән Программа нигезендә эшләнүе.

**Эчтәлекне үзләштерү барышында тәэмин ителергә тиешле эшчәнлек төрләре.**

• Гомумуку күнекмәсе буларак укуның төрле формалары – *гөжләп , сайлап, чылбырлап, кычкырып, эчтән* – даими кулланышка кую, уку тизлеге үсешен тәэмин итү. Сәнгатьле уку.

• Әдәби уку – әдәби әсәрнең персонажларын, авторының әсәр эчтәлегендә ничек катнашуын табу, персонажларның сыйфатларын һәм гамәлләрен аерып алу, гамәлләреннән чыгып бәя бирү, төп геройны табу, үрнәк яисә гыйбрәт ала белү күнекмәсе формалашуы өчен җирлек булдырылу. Әсәр текстын өлешләргә бүлү, охшаш өлешләрне гомумиләштерү, өлешләрне бәйләп куя торган сурәтләү алымнарын табу; әсәр өлешләренә исем бирү, план төзү. Әсәр эчтәлеген ачу. Авторның төп геройга мөнәсәбәтен ачыклау.

• Сөйләм (телдән). Укыганны текстка якын итеп, кыскартып үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү. Сөйләм этикеты кагыйдәләрен саклап, төрле характердагы коммуникатив ситуацияләрдә фикер алышуда катнашу. Хикәяләү, тасвирлау, үз фикереңне дәлилле яклау – монологик сөйләм күнекмәләренең камил формалашуы.

• Фикер эшчәнлеге: иҗади һәм фәнни фикерләү үсеше өчен җирлек тудырылу, фикерләүнең барлык формалары – чагыштыру, кабатлау, таркату, гомумиләштерү даими куланылышка куелу.

- Белем чыганаклары белән эшчәнлек, библиографик культура.
- Дәреслек, «Татар халык иҗаты» сериясеннән *«Табышмаклар», «Мәкальләр һәм әйтемнәр», «Әкиятләр»;* белешмә сүзлекләр: «*Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», «Татарча-русча сүзлек», «Татарча-русча фразеологик сүзлек», «Синонимнар сүзлеге».*

Вакытлы матбугат чаралары: *«Сабантуй», «Көмеш кыңгырау» газеталары, «Салават күпере», «Тылсымлы куллар» журналлары* белән эш күнекмәләре формалашу.Алфавит һәм тематик каталог белән мөстәкыйль эшчәнлек өчен җирлек тудырылу. Китапның исеме, әсәрләр исемлеге нигезендә бирелгән темага һәм үзе теләгән китапны сайлап алу. Әсәрләр җыентыгын автор китабыннан аерып тану.Укылган китапка бирелгән үрнәк нигезендә аннотация әзерләү.

- Иҗади эшчәнлек

Әсәрне рольләргә бүлеп уку. Геройларга бәя бирү. План нигезендә текст төзү. Әсәрдә куелган проблема нигезендә, рәсем нигезендә текст төзү. Вакыйгаларны автор исеменнән, герой исеменнән, үз исеменнән сөйләү. Үзләштерелгән әсәрне ятлау, сәнгатьле уку.

- Танып белү эшчәнлеге.

Белем алуда универсаль гамәлләрнең тотрыклы формалашуы өчен җирлек булдырылу:

а) регулятив гамәлләр формалашуы – уку мәсьәләсен кую *(мин нишләргә тиеш? дип уйлый белү);* чишү юлларын билгеләү *(ничек эшләп була? болай да, болай да була, тагын башкача эшләп булмыймы икән? дип улый белү);* эффектив булганын *(нәтиҗәгә җинел илтә торганын, уңаен)* сайлап ала алу; куелган мәсьәләне чишү*;* үз эшенә контроль ясый (*нишләргә тиеш идем әле, ничек эшләдем? дип кабат уйлый*) белү һәм үз эшенә адекват бәя бирә *(ничек булды? куелган максатка ирештемме? ни дәрәҗәдә ирештем? яки яхшымы, начармы? дигән сорауларга җавап бирә)* белү ;

б) танып белү гамәле – ысул белән коралландыру – укучыда нинди генә эшкә тотынса да эшләү ысулын аерып алу ихтыяҗы

формалаштыру. «Әдәби уку» дәресләрендә: *әдәби әсәрне уку ысулы, әдәби жанрны тану ысулы төрле белем чыганакларыннан файдалана белү күнекмәсе үсеше һәм эчтәлекнең модельләштерелүе (башкарылган эшнең кыскача, яки схемада язылышы) ;*

в) коммуникатив гамәлләр үсеше *(укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, этикет кысаларында әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белү)* – «Әдәби уку» дәресләрендә: *әсәрне укыганда геройларның гамәлләренә, сөйләгән сүзләренә, аларның әйләнә-тирәдәгеләргә йогынтысына (башка геройларга) бәя бирүе; тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә, этикет кысаларында башкалар фикерен кимсетмичә, дәлилле җиткерә белү күнекмәләре тотрыклы камилләшүе.*

**Үзләштерелергә тиешле әдәби пропедевтика.**

Әсәр, әдәби әсәр, халык авыз иҗаты әсәре, автор, герой, төп герой, ярдәмче герой, лирик герой, уңай һәм тискәре герой; автор фикере; жанрлар: табышмак, мәкаль, әйтем, мәзәк, мәсәл, әкият, шигырь, хикәя һәм аларның үзенчәлекләре; күренеш, эпизод, вакыйга, вакыйгалар үсеше, төенләнеш, чишелеш, сюжет, тема, автор фикере, әсәр эчтәлеге; сурәтләү чаралары – каршылык, охшашлык, арттыру.

**Эчтәлекне үзләштерү барышында тәэмин ителергә тиешле танып белү эшчәнлеген оештыру формалары:** парларда, төркемдә, фронталь.

**Эчтәлекне үзләштерү барышында тәэмин ителергә тиешле танып белү методлары:** проблемалы ситуация тудыру, өлешчә эзләнүле (эвристик), тикшерүле (исследовательский).

**Эчтәлекне үзләштерү барышында тәэмин ителергә тиешле контроль һәм бәя төрләре:** нигездә, үзконтроль, үзбәя.

Автомат дәрәҗәдә формалашырга тиешле гомумуку күнекмәләре:

Гөжләп, сайлап, чылбырлап, эчтән уку, кычкырып уку, укыганны үз сүзләрең белән сөйләү күнекмәләрен тотрыклы формалаштыру.

Кулланышка кергән төп төшенчәләрне татар һәм рус телендә үзләштерү.

Таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен табу ысулы - татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән алынган аңлатмаларны уку, истә калдыру күнекмәсе формалаштыру.

**Өстәмә белем чыганаклары белән эшчәнлек күнекмәсе:**

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.

Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел;

## Танып белү эшчәнлеген оештыру формасы – дәрес. Дәрес структурасы:

## Иҗади үсеш технолгиясенә корылган дәрес структурасы

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

Бу этапта башкарылырга тиешле эшчәнлек адымнары:

1. Өй эшләренә анализ. Кайсы өй эшен, ничек эшләгәннәр. Иң яхшы эш кемнеке, ни өчен?

2. Белемнәрне тигезләү - актуальләштерү, ягъни бүгенге тема ны үзләштергәндә кулланышка керергә тиешле, инде үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү, барлык балаларны-да бер яссылыкка кую, яңа белем, күнекмәләрне үзләштерүгә бер дәрәҗәдә әзер итү .

3. Уку мәсьәләсен - бүгенге дәрестә үзләштерелергә тиешле бе лем, күнекмәлерне конкретлаштыру ситуациясе тудыру (Уку мәсьәләсе = дидактик максат). Бу – дәреснең бик мөһим мизгеле: белгән белән белмәгәннең чиген ачыклау - мотивлаштыру процессы.

**II. Уку мәсьәләсен (УМ) адымлап чишү этабы.**

1. Уку мәсьәләсен (укытучы проблемалы сорауларга һәм биремнәргә бүлә - УМ = 1,2,3) адымлап чишү оештырыла: һәр бирем чишелә→нәтиҗә аерып алына→бергәләп→бер-берсенә→үз-үзләренә сөйләнә→нәтиҗәләр гомумиләштерелә →Укытучы критерий бирә→ Укучылар үзбәя куя.

Гомумиләштерелгән нәтиҗә ($н_1 + н_2 + н_3 = Н$) УМ нең

чишелеше була.

2. Модельләштерү - ысул аерып алу, дәрестә башкарылган эшне кыскача язуда күрсәтү.

**III. Рефлексия, бәя этабы.**

1.Рефлексия - дәрестә узган юлны кире узу.

Ягъни нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә);ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә); нинди нәтиҗә ясадык? ($Н = н_1 + н_2 + н_3$), дигән сорауларга җавап бирү.

2. Дәрестәге эшчәнлеккә үзбәя.

Укытучы критерий бирә, шул нигездә балалар үз-үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийгә туры килүен билгелиләр.

Искәрмә:Универсаль критерий: Нәрсә эшләргә тиеш идек? Ничек эшләдек? Нинди нәтиҗә ясадык? дигән сорауларга

а) терәк конспекттан, (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып кына сөйләп бирә алса - «3»;

б) терәк конспектка күз төшергәләп кенә сөйли алса - «4»;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча, сөйли алса - «5».

3. Өйгә эш алу.

Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә:

- репродуктив эшчәнлеккә, ягъни класстагы эшкә охшаш, үзләштерелгән белем һәм күнекмәләр таләп ителгән эш (бу эш мәҗбүри - һәркем эшләргә тиеш);
- конструктив эшчәнлеккә - ярым иҗади, ягъни, белем һәм күнекмәләрне аз гына яңа шартка күчерүне таләп иткән эш; бу бирем ихтыярый;
- иҗади эшчәнлеккә, ягъни белем һәм күнекмәләрне яңа җир лектә куллану өчен бирелә; бу эш тә ихтыярый.

**Укучыларның танып белү эшчәнлеге иҗади үсеш технологиясенә корылганда дәрестән дәрескә түбәндәге нәтиҗәлелек тәэмин ителә:**

**1.Махсус белем һәм күнекмәләрнең тотрыклы формалаша.**

Дәрестән дәрескә әдәбият предметы буенча теоретик белем киңәя, кулланышка алынып махсус күнекмә формалашуга, камилләшүгә китерә.

Әсәр текстына кайта-кайта куелган проблемалы сорау һәм биремнәргә җавап эзләгәндә, укучының гомумуку күнекмәләре: аңлы уку тизлеге, фикер эшчәнлеге, фикерен иптәшләренә җиткерә белү күнекмәләре дә формалаша, тотрыклылык ала.

2. Образлы һәм фәнни фикерләү күнекмәсе тәэмин ителә. Укучы чагыштыру, таркату, гомумиләштерү кебек фикерләү ысулларын даими куллана.

3. Белем алуда универсаль гамәлләрнең тотрыклы формалашуы өчен җирлек булдырыла

4. Игътибарлылыгы (*күңел күзе*), хәтере (*үзләштергән белем күнекмәләре тотрыклылана*) үсә.

5. Белем чыганагы («Әдәби уку» дәреслеге, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», «Татарча-русча сүзлек») белән эш күнекмәсе тотырыклы формалаша.

6. Сәламәтлегенә - физик һәм психологик халәтенә мәктәп тормышы тискәре йогынты ясамый: укучының һәр әгъзасы - баш мие, умыртка баганасы, күзләре, куллары, теле даими хәрәкәттә; укучы тыңлый, ишетә, күрә, уйлый, сөйли, яза һ. б.; киеренкелеккә урын калмый, чөнки ул ялгыз түгел - ул сыйныфташлары, укытучысы, белем чыганаклары (дәреслек, төрле белешмә сүзлекләр, укучының эш дәфтәрендәге язмалары) ярдәмендә белем үзләштерә. Бала кече яшьтән бик кыйммәтле хакыйкатьне танып белү ситуациясенә куела: уңыш һәм уңышсызлык кешенең үзеннән тора.

**Башлангыч сыйныф укучыларының уку эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күрсәтүче гомумуку күнекмәләренең берсе – уку тизлеген тикшерү, анализ ясау һәм бәяләү.**

Уку тизлеген тикшерү методикасы

*Искәрмә:* Һәр баланың уку тизлеген башлангыч сыйныф укытучысы үзе тикшерә. Шул ук вакытта балаларның үзләренә дә бу методиканы әкренләп өйрәтү кирәк. Беренчедән бу кызыклы, икенчедән – белем бирүдә федераль стандарт таләпләре шулай куша: укучыны без үзконтрольгә, үзбәягә өйрәтергә бурычлы. Моның өчен ысул өйрәтү зарур.

**Текстка таләпләр:**

Кечкенә күләмле, укучыга таныш булмаган 2 әдәби әсәр (беренче һәм икенче вариант өчен) алына.

**Тикшерү процессын оештыру тәртибе:**

Балалар парларда бер-берсенең уку тизлеген тикшерәләр. Укучылар белән уку тизлеген тикшерү ысулы алдан үзләштерелә, тикшерү күнендә тагын бер кабат ныгытыла.

Укучы текстны тулысынча һәм эчтәлеген аңларга тырышып, шул ук вакытта тиз укып чыга.

Күрше укучы уку техникасын күзәтә, 1 нче таблицага теркәп бара: 3,4,5,6,7,8 графаларга «+» яки башка тамга куя; вакытны « t » минутларда билгели

Мисал өчен, Марат иҗекләп, ә Ринат сүзләп укый, ди

**Уку техникасына һәм тизлегенә анализ**

**(**1нче таблица, һәр пар өчен алдан әзерләнеп таратыла)

| т/с | Укучының Ф.И. | уку ысулы | | | үзенчәлекле кимчелекләре | | | сентябрь | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хәрефләп | иҗекләп | сүзләп | иҗек өсти | иҗекне төшереп калдыра | сүзне кабат-кабат укый | Q | t | k | V | Бәя |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | Галиев М. | - | + | - | + | - | + | | | | | |
| 2. | Йосыпов Р. | - | | + | - | - | - | | | | | |

*Искәрмә: Шушы күзәтү нәтиҗәсеннән чыгып, алга таба уку тизлеген үстерү һәм уку техникасын камилләштерү максатында индивидуаль эшчәнлек алып барылырга тиеш була.*

Ике вариант та бирелгән текстны укып чыккач, укытучы фронталь эш башлый?

- язмача җавап бирү өчен сораулар бирелә;
- сорауларга җавап язу өчен вакыт бирелә.

*Сорауларга җаваплар эш дәфтәренә языла.*
*Дәфтәрләр һәм 1нче санлы таблицалар җыеп алына.*

**Уку тизлеге нормасы, бәя** *( 2,3 нче таблица)*

| сыйныф | I ярты ел | | | II ярты ел | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | нормадан югары | норма | нормадан түбән | нормадан югары | норма | нормадан түбән |
| I | 30дан югары | 10-30 | 10 нан түбән | 50дән югары | 30-50 | 30дан түбән |
| II | 60 тан югары | 40-60 | 40 тан түбән | 80 нән югары | 50-80 | 50 дән түбән |
| III | 100 дән югары | 60-100 | 60 тан түбән | 130 дан югары | 60-130 | 60 тан түбән |
| IV | 140 тан югары | 70-140 | 70 тән түбән | 150 дән югары | 80-150 | 80 нән түбән |

| сыйныф | I ярты ел | | | II ярты ел | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «5» | «4» | «3» | «5» | «4» | «3» |
| I | 30 | 20 | 10 | 50 | 40 | 30 |
| II | 60 | 50 | 40 | 80 | 70 | 50 |
| III | 100 | 80 | 60 | 130 | 100 | 60 |
| IV | 140 | 110 | 70 | 150 | 120 | 80 |

**Уку тизлеге түбәндәгечә исәпләнә:** $V = \frac{Q}{t} \times k$

Q - *тексттагы сүзләр саны (барлык укучы өчен дә бер үк була)*
t - *укучының текстны укып чыгу вакыты*

k - *аңлау коэффициенты, ул укытучы биргән сораулар аша ачыклана*

Әгәр бирелгән сорауларга җаваплардан чыгып, укучы укыган текст эчтәлеген 100 % аңлаган, дигән нәтиҗә ясалса, k – 1 балл була; 90 % - k = 0,9; 80 % - 0,8; 70 % - 0,7; 60% - 0,6; 50 % - 0,5; 40 % - 0,4; 30 % - 0,3; 20 % - 0,2; 10 % -0,1.

**Уку тизлегенә гомуми анализ** *(4нче таблица)*

| т/с | Укучының Ф.И. | сентябрь | | | | | декабрь | | | | | апрель-май | | | | | чагыш-тырма нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Q | t | k | V | Бәя | Q | t | k | V | Бәя | Q | t | k | V | Бәя | |
| 1. | Галиев М. | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | һ.башка-лар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| гомуми күрсәткеч | нормадан югары | — укучы | | | | | | | | | | | | | | | - - укучы - % |
| | норма | — укучы | | | | | | | | | | | | | | | - - укучы - % |
| | нормадан түбән | — укучы | | | | | | | | | | | | | | | < > - - укучы - % |
| | өлгереш (%) | (%) | | | | | | | | | | | | | | | |
| | сыйфат (%) | (%) | | | | | | | | | | | | | | | |

**Искәрмә:** Гомуми күрсәткечне исәпләү өчен **өлгереш (%)** = 100% : барлык балалар саны x «5», «4», «3» билгеләре алган укучылар саны; сыйфат (%) = 100% : барлык балалар саны x «5», «4» билгеләре алган укучылар саны.

**«Әдәби уку» («Татар әдәбияты») курсының уку планындагы урыны**

«Әдәбият» системага куелган курс буларак «Әлифба» чоры тәмамлану белән, 1нче сыйныфтан башлана.

«Әдәби уку» курсы 224 сәгатькә исәпләнгән:

- 1нче сыйныфка 20 сәгать *( атнага 2 шәр сәгать, 10 уку атнасы);*
- 2 нче сыйныфка 70 сәгать *( атнага 2 шәр сәгать, 35 уку атнасы);*
- 3нче сыйныфка 70 сәгать ( атнага 2 шәр сәгать, 35 уку атнасы);
- 4 нче сыйныфка 70 сәгать ( атнага 2 шәр сәгать, 35 уку атнасы).

**1нче СЫЙНЫФ (20 сәгать)**
**Тематик план**

| | |
|---|---|
| Структур берәмлекләр | Эчтәлек (СОДЕРЖАНИЕ) |
| Бүлек темасы | «Әдәбият» дәресләренең эше |
| Сәгать саны | 2 сәгать |
| Үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | «Әдәбият» дәреслегендә ориентлашу: шартлы билгеләрнең эчтәлеген адымлап үзләштерү, куллану күнекмәләре формалаштыру.<br>«Әдәбият» дәресләренең эшен (әсәрләрне укый белергә өйрәнү булуын) үзләштерү.<br>Әдәби әсәрне укый белү күнекмәсе формалаштыру: игътибар белән укыйм, әсәрнең исеменә, тыныш билгеләренә игътибар итәм. Авторын истә калдырам |
| Кулланылган әсәрләр | 1) Балаларга инде балалар бакчасыннан ук таныш рус халык әкияте «Бүре һәм кәҗә бәтиләре»;<br>2) Габдулла Тукай «Бәхетле бала» |
| ТР дәүләт телләрендә үзләштерелергә тиешле төп төшенчәләр | Әдәби уку- литературное чтение<br>Әсәр - произведение |
| Гомумуку күнекмәләре | Гөжләп, сайлап, чылбырлап, эчтән уку күнекмәләрен үстерү.<br>Кулланышка кергән төп төшенчәләрне татар һәм рус телендә үзләштерү<br>Таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен табу ысулы - татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән алынган аңлатмаларны уку, истә калдыру күнекмәсе формалаштыру. |
| Өстәмә белем чыганаклары | Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; |

| | |
|---|---|
| | III том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.<br>Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел |
| Иҗади эш | – |
| Контроль эш | Уку тизлеген тикшерү |

| | |
|---|---|
| Структур берәмлекләр | Эчтәлек |
| Бүлек темасы | Әдәби әсәрдә катнашучылар |
| Сәгать саны | 16 сәгать |
| Үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | «Персонаж», «Автор», «Укучы», терминнарын кулланышка кертү. Әдәби әсәрнең катнашучылары кешеләр, хайваннар, кош-кортлар, төрле предметлар, сүзләр, авазлар, тыныш билгеләре дә (теләсә нәрсә) була алуын, әмма әдәби әсәр кешеләр, аларның әйләнә-тирә дөньяга мөнәсәбәте турында гына булуын үзләштерү. Әсәрне язган кешенең «Автор», әсәрне укучы кешенең «Укучы» дип аталуын; аларның да әдәби әсәрнең катнашучылары булуын үзләштерү. Әдәби әсәрнең персонажларын таба белү, авторның ничек итеп катнашуын аңлатып бирә белү күнекмәсе формалаштыру. Укучының әсәр аша нинди үрнәк, яисә гыйбрәт алуын аңлатып бирү күнекмәләре формалаштыру. Әдәби әсәрне укый белү ысулын үзләштерү. Укыганны («сюжет» терминын әлегә кертмибез) үз сүзләре белән текстка якын итеп, кыскартыбрак һәм бик кыска итеп сөйләп бирүнең беренчел күнекмәсен формалаштыру. Үзләштерелгән белемне модельләштерүнең беренчел күнекмәләрен формалаштыру |
| Кулланылган әсәрләр | Габдулла Тукай «Гали белән кәҗә» |
| ТР дәүләт телләрендә үзләштерелергә тиешле төп төшенчәләр | Катнашучылар- действующие лица, автор – автор, әсәрне укучы - читатель, персонаж - персонаж |

| | |
|---|---|
| Гомумуку күнекмәләре | Гөжләп, сайлап, чылбырлап, эчтән уку күнекмәләрен үстерү.<br>Кулланышка кергән төп төшенчәләрне татар һәм рус телендә үзләштерү.<br>Таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен табу ысулы - татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән алынган аңлатмаларны уку, истә калдыру күнекмәсе формалаштыру. |
| Өстәмә белем чыганаклары | Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.<br>Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел. |
| Иҗади эш | Й. Шәрәпованың «Җиңү» әсәре нигезендә бирем |
| Контроль эш | Әсәрне укырга, персонажларын табарга. Ничек тапканны аңлатырга. А.Гатуфның «Карандаш белән бетергеч»әсәре буенча |

| | |
|---|---|
| Структур берәмлекләр | Эчтәлек |
| Бүлек темасы | Дәрестән тыш уку |
| Сәгать саны | 1сәгать |
| Үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | Әдәби әсәрне укый белү күнекмәләрен үстерү.<br>Укыганны («сюжет» терминын әлегә кертмибез) үз сүзләре белән текстка якын итеп, кыскартыбрак һәм бик кыска итеп сөйләп бирүнең беренчел күнекмәсен үстерү.<br>Үзләштерелгән эчтәлекне модельләштерүдә беренчел күнекмәләрне ныгыту |
| Кулланылган әсәрләр | |

| | |
|---|---|
| Гомумуку күнекмәләре | Китапханә белән таныштыру.<br>Таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен табу ысулы - татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән алынган аңлатмаларны уку, истә калдыру күнекмәсен үстерү |
| Өстәмә белем чыганаклары | Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. -Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.<br>Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. -Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел |
| Иҗади эш | Й. Шәрәпованың «Җиңү» әсәре нигезендә бирем |
| Контроль эш | Әсәрне укырга, персонажларын табарга. Ничек тапканны аңлатырга. А.Гатуфның «Карандаш белән бетергеч»әсәре буенча |

## Дәрес темалары

**Кереш.**

1. «Әдәбият» дәресләренең эше (Бәхетле бала).

2. Әсәр белән эш (Бүре һәм кәҗә бәтиләре. Рус халык әкияте).

**Әсәрдә катнашучылар**

1 . Әсәрнең катнашучысы – автор (Гали белән кәҗә).

2. Әсәрнең катнашучылары – без (укучы –читатель).

3. Әсәрнең катнашучылары – кыз бала (Гөлнар мәктәпкә бара).

4. Әсәрнең катнашучылары – үсемлек (Тузганак)

5. Әсәрнең катнашучылары –йорт хайваны (Макай белән Акбай).

6. Әсәрнең катнашучылары – кош-кортлар (Кара тавык, ак тавык).

7. Әсәрнең катнашучылары – тыныш билгеләре (Тукта! Ник качасың?)

8. Әсәрнең катнашучылары – бала һәм су, тузан (Җиңү).

9. Әсәрнең катнашучылары – уку әсбаплары (Карандаш белән Бетергеч).

10. Әсәрнең катнашучылары – сүз (Карлы-карсыз карбыз).

11. Әсәрнең катнашучылары – авазлар (Салкын аваз).

12. Персонаж (Кабатлау, гомумиләштерү дәресе).

13. Әсәрнең сере (Куян зары).

14. К/э. Әсәр һәм аның персонажлары (Йомгаклау дәресе. Әсәрне уку ысулы).

15. Хаталар өстендә эш.

16. Класстан тыш эш.

17. Яттан сөйләү (Үзе теләгән әсәр).

18. Уку тизлеге (Тиен һәм бүре).

**Еллык контроль эш (**1 класс ахыры).

**Бирелгән әсәрне игътибар белән укы** . Катнашучыларны күрсәтергә әзерлән.

**Карандаш белән Бетергеч**

Карандаш белән Бетергеч дуслашканнар. Бергә уйнаганнар, бергәләп дәрес әзерләгәннәр. Карандаш каты күңелле булган, ә Бетергеч йомшак күңелле икән. Карандаш ямьсез сүзләр яза башласа, Бетергеч аларны берәү дә сизмәслек итеп боза барган. Матуррак, дөресрәк итеп язарга өйрәнгәнче Карандашка шулай ярдәм итеп торган. Карандаш дустына рәхмәтләр әйтеп туя алмаган. Шулхәтле ярдәм итүчегә кем рәхмәт укымасын! Дуслар бер тапкыр да үпкәләшмәгәннәр, ел буена тату яшәгәннәр.

Танышлары дусларның тату яшәвенә көнләшкәннәр. Каләм исемле бер танышы Карандашны:

— Бетергеч белән дуслашып ялгыштың. Ул бит синең һәр сүзеңне юкка чыгарып бара. Шулай бетерә-бетерә ул сине тәмам хур итеп бетерәчәк! — дип котырткан.


Ә Бетергечне Пәке үчекләгән:

— Ашыгып дуслаштың ул Карандаш белән. Яза-яза акылдан яздырачак әле ул сине! — дигән.

Карандаш, ямьсез сүзләрне кабат яза башлаган. Ә Бетергеч аны бетерми, төзәтми икән.

Каләм белән Пәке дусларның шулай тиз арада аерылганын күреп шаккатканнар. «Нигә болай булып чыкты соң әле бу?» — дип аптырашканнар. (146 сүз) Альберт Гатуф.

**Әсәрдә катнашучыларны бирелгән модельдә күрсәт.**



**4 нче сыйныф ахырында алынырга тиешле контроль эш**

**Дидактик максат:** Башлангыч сыйныф укучыларның әдәби әсәр белән эш күнекмәләрен тикшереп, әдәбият теориясе буенча программа таләп иткән махсус белем һәм күнекмәләре сыйфатын ачыклау.

**Үстерешле максат:** Әдәбият теориясе һәм предметара белем һәм күнекмәләре нигезендә фикерләүнең төрле төрләре һәм формалары үсешен; универсаль гамәлләр: регулятив, коммуникатив, танып-белү гамәлләренең формалашу дәрәҗәсен ачыклау.

**Тәрбияви максат:** Персонажларга аларның гамәлләренә карап бәя бирелүдән чыгып, укучыларның гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәтләрен (*әхлаклылык дәрәҗәләре үсешен*) ачыклау.

**Кулланылган әсәр:** Р.Батулланың «Карурманга бара Мөбарәк» хикәясе.

**Әсәрнең максатка ярашлы булуы күрсәткечләре:**

- Темасы сине чолгап алган дөнья (якын кешеләрең, табигать) белән мөнәсәбәт матурлыгы яшь үзенчәлекләре – кече яшьтәге укучының тормыш тәҗрибәсе кысаларына сыйдырылган.
- Кыска, әмма тирән эчтәлекне сыйдырган сюжет (174 сүз).
- Сине чолгап алган дөнья белән мөнәсәбәт нинди булырга тиеш? дигән проблема күтәрелгән.
- Мөбәрәк исемле ярдәмчел ( апасына ярдәм итү өчен кичкә каршы карурманга - билгесезлек белән чолганган урынга бер ялгызы барырга әзер) малай һәм карурманда яшәүчеләр образы , аларның бер-берсенә мөнәсәбәте аша гаҗәеп чишелеш тәкъдим итә: Мөбәрәк кебек чиста күңелле, ихлас булырга, әйләнә-тирә серләрен яхшы өйрәнергә, тәвәккәл, кыю булырга, ди.
- Идеясе матур һәм үтә көнүзәк: Эх, барлык малайлар һәм кызлар да Мөбәрәк кебек якын кешеләре өчен ярдәм итәргә әзер чиста күңелле булсын иде, табигать серләрен яхшы белсеннәр иде дә, зыян салмый гына урынлы файдалансын иде.
- Әсәрдә персонажлары күп һәм төрле булуы укучыларның

таркату, гомумиләштерү кебек фикерләү күнекмәләре дәрәҗәсен һәм образлы фикерләү дәрәҗәсен ачыкларга мөмкинлек бирә;

- Хикәянең эчтәлеге тирән: персонажларның гамәлләреннән чыгып бәя бирү аша укучыларның гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәтләрен ачыкларга ярдәм итә.

**Искәрмә:** Контроль эш тексты һәм биремнәре Һәр укучыга А-4 форматлы кәгазьдә таратыла. Контроль эш таратылган А-4 форматлы кәгазьдә башкарыла.

**Карурманга бара Мөбарәк**

Мөбарәкнең апасы авырып китте. Суга барганда таеп егылган да аягын каймыктырган. Күрше әби әйтә:

- Хәзер үк җир мае белән сыпырырга кирәк! –ди .

-Каян табасың инде ул җир маен?- диде Мөбарәкнең әнисе.

-Урманда юан юкә төбендә җир мае бар! Үзем күрдем,- диде Мөбарәк. Минем йодрык чаклы бар. Алып кайтыйммы?

-Үзең генә урманга барырга курыкмыйсыңмы соң? – диде күрше әби. Кич җитеп килә бит.

-Куркуын куркам да... Апага җир мае кирәк бит. Җир маена бармасам, апаның аягы тиз төзәлмәс, -диде дә Мөбарәк урманга китте.

Яктырткыч коңгызлар Мөбарәкнең юлын яктыртып барды. Мөбарәк юан юкәне тиз тапты. Җир мае ул гөмбәгә охшаган була. Гөмбә кебек булса да ул: мине күрегез, дип чекрәеп тормый. Яфрак астына яшеренеп үсә. Аны исеннән эзләп табалар.

Яфрак юрганын актарганда, Мөбарәкнең кулы җир маена тиде.Салкынча лайлалы, шома, түп-түгәрәк җир маен алып, Мөбарәк кайтырга чыкты.

-Курыкма, Мөбарәк! – ди Ябалак.

-Курыкма, Мөбарәк! – ди Аю.

-Курыкма, Мөбарәк! – ди кошлар.

Яктырткыч коңгызлар, Мөбарәкнең кайтыр юлын яктыртып, Мөбарәкне озата бара. Мөбарәк тиз кайтып җитте. Хуш исле салкын җир мае белән Мөбарәкнең апасының авырткан аягын ышкыдылар.

Батыр икәнсең син, Мөбарәк, - диде күрше әби.

Батулла


**Еллык контроль эш.**

**Укучының фамилиясе, исеме:**

____________________________________________

**Бирелгән әсәрне игътибар белән укы, түбәндәге биремнәрне үтә.**

**1**. Катнашучыларны тап. Персонажларны гомумиләштер. Катнашучыларны бирелгән модельдә күрсәт.



**2**. Катнашучыларның гамәлләрен яз.

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

3. Персонажга бәя бир.

I –вариант

Җир мае ____________________________________

____________________________________________

____________________________________________

II–вариант


Мөбәрәк____________________________________

**4**. Әсәрнең идеясе нинди?

____________________________________

**Үзконтроль һәм үзбәя өчен көтелгән җаваплар.**

**1** нче биремнең көтелгән җавабы:




**2** нче биремнең көтелгән җавабы:

**Катнашучыларның гамәлләре:**

**Кешеләр -** авыруга дәва эзлиләр һәм урманнан алалар.

**Киекләр, бәҗәкләр** - кешеләргә теләктәшлек күрсәтәләр, ярдәм итәләр.

**Үсемлекләр -** кешене дәвалый, ярдәм итәләр.

**Урман** - кешеләргә файдалы үсемлекләрне үстерә, киекләр, бәҗәкләр анда яши.

**Автор** - Апасына ярдәм итәргә әзер торучы, күп белгән, кыю малай - Мөбәрәккә Карурманда яшәүчеләрнең дә ничек булышуы турында сөйли.

**1 вариант җавап:**

**Укучы** – укый, яңа мәгълүмат ала, фикерли, нәтиҗә ясый: чиста күңелле, ярдәмчел булырга; табигатьне өйрәнергә, урынлы һәм сак файдаланырга кирәк

2 нче вариант җавап:

**Укучы –** әсәрне укып, автор белән сөйләшә: яңа мәгълүмат ала, фикерли, нәтиҗә ясый: чиста күңелле, ярдәмчел булырга; табигатьне өйрәнергә, урынлы һәм сак файдаланырга кирәк. Якын

кешеләреңә ярдәм кирәк булганда кыю бул. Шулай булганда «карурман» да яшәүчеләр дә сиңа ярдәм итә!!

3 нче биремнең күтелгән җавабы:

I –вариант

Җир мае урманда юкә агачы төбендә үсә.

Ул гөмбәгә охшаган, түп-түгәрәк, йодрык чаклы гына, салкынча лайлалы, бераз шыксыз була инде; шома, исле. Чекрәеп тормый, яшеренеп үсә, димәк мактанчык түгел, ә үзе бик файдалы – кешеләргә дәва бирә.

II–вариант

Мөбәрәк апасын бик ярата, кичкә каршы урманга барырга курыкса да бара. Ул табигатьне дә ярата, аның серләрен белә. Шуңа күрә дә урман киекләре дә, бөҗәкләр дә аңа ярдәм итә. Ярдәмчел дә, батыр да. Күрше әби аңа соклана. Әнисе белән әбисе горурланалардыр.

4 нче биремнең күтелгән җавабы:

Әсәрнең идеясе:

Эх, барлык малайлар һәм кызлар да Мөбәрәк кебек табигатьне яхшы белсеннәр иде дә, зыян салмый гына урынлы файдалансын иде.

**Бәяләү критерийлары һәм үлчәү берәмлекләре.**

1 нче бирем: 37 балл.

- катнашучылар дөрес табылган (14 катнашучы х 1 балл =14 балл);
- персонажларны гомумиләштерү дөрес(5төркем персонаж х1балл= 5 балл;
- катнашучылар модельдә дөрес урнаштырылган ( 18 катнашучы х 1балл = 18 балл;

**2 нче бирем: 16 балл.**

Кешеләрнең гамәлләре дөрес: 2балл;

Киекләр, бөҗәкләрнең гамәлләре дөрес: 2балл;

Үсемлекләрнең гамәлләре дөрес: 2балл;

Урманның гамәле дөрес: 2балл;

Авторның гамәле дөрес: 2балл;

Укучының гамәле 1 нче варианттагы кебек: 3балл;

2 нче варианттагы кебек**:** 5балл.

**3 нче бирем: 15 балл.**

Персонажга дөрес бәя бирелгән: 15 балл.

**4 нче бирем: 15 балл.**

Әсәрнең идеясе дөрес бирелгән: 15 балл.

**Максималь балл: 83.**

81- 83 балл - «5»ле 42 -60 балл - «3»ле

61- 80 балл - «4»ле 41балл һәм аннан да түбән-»2»ле

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе
Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
«52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»

Расланды:
Педагогик берләшмә беркетмәсе
« 28 « август 2013 ел № 1
№ боерык белән гамәлгә кертелде 28.08. 2013 ел
Мәктәп директоры: С.Р.Кайбышев
имза

**«Әдәбият» уку предметынннан эш программасы**

(5 нче татар сыйныфы өчен атнага 3 сәгать, елга 105 сәгать)

Төзүче: Хәсәншина Рәзидә Гатаулла кызы, югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Килешенде: 28.08. 2013
Директор урынбасары: Д.В. Баһаутдинова
имза
Каралды : 27.08. 2013
МБ утырышы беркетмәсе: 2013 ел № 1
МБ җитәкчесе : В.Г. Хәйдәрова
имза

Яр Чаллы, 2013

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныф өчен татар әдәбиятыннан эш программасы «Татар телендә урта белем бирү  мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программасы»на (Төзүчеавторы: А.Г.Яхин) нигезләнеп төзелде. А.Г.Яхин программасы «Татар телендә урта белем бирү  мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан  үрнәк программалар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011) җыентыгына кертелгән һәм белем бирүдә федераль дәүләт стандарты (ФГОС) таләпләренә җавап бирә.

Дәреслек: А.Г.Яхин. Әдәбият, 5. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2005.

Программа нигезендә 5 нче сыйныфта татар әдәбиятын өйрәнүгә атнага 2 сәгать исәбеннән 70 сәгать каралган. Ә укыту планы буенча атнага 3 сәгать исәбенән 105 сәгать бүленгән. Шул сәбәпле теорияне үзләштерү һәм файдаланырга өйрәнү, иҗади эшләр һәм күнегүләргә сәгатьләр саны артыграк бирелде.

5 нче сыйныфта әдәби әсәр төзелеше, каршылык бәйләнеше, сәнгать алымнары, хис төшенчәсе, экият, мәкаль, әйтем, халык җырлары, мәзәк һәм мәзәкчә, табышмак, мифлар кебек жанрлар өйрәнелә. Укучылар, үзләштергән теорияне файдаланып, әсәргә анализ ясарга өйрәнәләр.

## Программаның эчтәлеге

Кереш – 1 сәгать
Сәнгать алымнары – 28 сәгать:
Чагыштыру – 4 сәгать
Каршылык – 7
Сыйфат дәрәҗәсе – 9
Кабатлау – 2
Мәгънә – 4
Метафора – 4
Хис – әдәби әсәр эчтәлеге – 25 сәгать
Күнегүләр – 27 сәгать
Кабатлау – 4 сәгать
*Барысы – 87 сәгать*

**Бәйләнешле сөйләм үстерү һәм язма эшләр**

Сочинение – 6 сәгать
Контроль эш – 2 сәгать
Хаталарны төзәтү өстендә эш – 1 сәгать
Мөстәкыйль эш – 4 сәгать
Дәрестән тыш уку – 5 сәгать
Барысы – 18 сәгать

Гомуми сәгатьләр саны – 105

## Календарь-тематик план

*Хәсәншина Рәзидә Гатаулла кызы*

## Татар әдәбияты, 2013-2014 нче уку елы

План «Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар» (1-11 нче сыйныфлар, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011. Басма өчен Г.Р.Галиуллина, Д.Ф.Заһидуллина җаваплы) җыентыгыннан

«Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программасы» (Төзүче-авторы:А.Г.Яхин), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011) нигезендә төзелде.

| Предмет | Сыйныф | Барлык сәгать саны | Атналык сәгать саны | Сөйләм үстерү (сәгатьләрдә) | | Дәреслек авторы, чыккан елы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Соч. Кон. эш Мөс.эш Дәр.т.уку | Хата өс. эш | |
| Әдәбият | 5 | 105 | 3 | 6 2 4 5 | 1 | А.Г.Яхин, 2010 нчы ел |

**2013-2014 нче уку елына методик тема**

| Шәһәр | Мәктәп | Укытучы |
|---|---|---|
| Федераль дәүләт белем бирү стандартын тормышка ашыруда укытучының һөнәри осталыгын үстерүдә методик ярдәм. | Федераль дәүләт белем бирү стандартын үзләштерү шартларында педагогның һөнәри осталыгы үсеше белән идарә | Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион УМК ярдәмендә укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү |

**Каралды:**
МБ утырышында
2013 елгы № 1 беркетмәсе
МБ җитәкчесе: Хәйдәрова В.Г.
Дата 27. 08. 2013

**Килешенде:**
Директор урынбасары:
Баһаутдинова Д.В.
Дата 29 08. 2013

## Тематик план

| Т\ с | Дәрес темалары | Сәг. саны | Үтк. вак. | Планлаштырылган нәтиҗәлек | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Махсус белем һәм күнекмә | Гомум уку күнекмәсе |
| 1 | Кереш.Әдәбият дәресләренең максаты | 1 | | | |
| | Сәнгать алымнары | 28 | | | |
| 2 | Сәнгать алымнары: чагыштыру, каршылык | 1 | | Сәнгать теле турында төшенчә бирү | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 3 | Сыйфат дәрәҗәсе, кабатлау, мәгънә | 1 | | Сәнгать алымнары белән таныштыру | Күмәк танып белү эшчәнлегендә актив катнашу |
| 4 | Шәүкәт Галиевнең «Кем белә?» «Чабалар», «Атлап чыктым Иделне» шигырьләрендә чагыштыру юлы белән бәя бирү | 1 | | Чагыштыру ысулын әсәрдән эзләп таба белү күнекмәсен үстерү | Текст белән эшләү күнсен үстерү |
| 5 | Г. Тукайның «Баскыч» шигырендә чагыштыру аша бәя бирү | 1 | | Чагыштыру аша бәя биргәндә, бөтеннең үз эчендә каршы якларга бүленүе ярдәмендә анализ ясау | Иҗади күзаллау күнекмәсе үстерү |
| 6 | «Бәхетле», «Балыкчы» мәзәкләрендә чагыштыру юлы белән бәя бирү | 1 | | Чагыштыру юлы белән сыйфат дәрәҗәсен күзәтүгә мөмкинлек бирү | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 7 | «Хәйләкәр әтәч» әкиятендә каршылык аша бәя бирү | 1 | | Каршылыкның 2 төрен аера белү күнекмәсен камилләштерү | Сәнгатьле сөйләү күнекмәсен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | «Төлке белән торна», «Әләкче» әкиятләрендә каршылык аша бәя бирү | 1 | | Каршылыкны әсәрдән эзләп табу, файдалана белү күнекмәсен үстерү | |
| 9 | Б.с.үстерү. Иҗат эше: әкиятнең дәвамын  язу | 1 | | Сәнгатьле фикерләү сәләтен үстерү | Бәйләнешле,эзлекле язу күнекмәсен үстерү |
| 10 | Ябалак», «Акыллы килен» әкиятләрендә вакыйга үзгәрү тудырган каршылык | 1 | | Каршылык төрләрен аера белү күнекмәсен үстерү | Текст белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 11 | Г. Тукайның «Күгәрчен» шигырендә каршылык (күнегү) | 1 | | Әсәрне өлешләргә бүлү күнекмәсен үстерү | Үз фикереңне дәлилли белү күнекмәсен үстерү |
| 12-13 | Г. Тукайның «Таз» шигырендә вакыйга үзгәрү тудырган каршылык | 2 | | Каршылыкны әсәрдән эзләп табу күнекмәсен кам-рү | Сәнгатьле итеп яттан сөйләү күнекмәсен үстерү |
| 14 | Ш. Галиевнең «Надан», З. Бәширинең «Яхшылык» шигырьләрендә мәгънә | 1 | | Мәгънә турында төшенчә формалаштыру | Бәяли белү күнекмәсен камилләштерү |
| 15 | Дәрдемәнднең «Богдай» хикәясендә мәгънә (күнегү) | 1 | | Әсәрнең эчтәлеген табу күнекмәсен үстерү | Иптәшеңнең җавабын тыңлый белү күнекмәсен үстерү |
| 16 | И.Низамовның «Теш үтмәгәч» хикәясендә мәгънә (158 нче бит) | 1 | | Вакыйгаларның мәгънәләрен табу | |
| 17 | Әйтемнәрдә мәгънә | 1 | | М.Әмирнең «Агыйдел»,Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» әсәрләреннән әйтемнәрне табу | Текст өстендә эшләү күнекмәсен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Б.с. үстерү. Мөст.эш. Хикәяне әйтемнәр белән баетып язу | 1 | | «Урманда» хикәясен әйтемнәр белән баетып язу. 22 б | Иҗади фикерләү сәләтен үстерү |
| 19 | Мәкальләрдә мәгънә | 1 | | М Галәүнең «Болганчык еллар» әсәреннән мәкальләр табу | Текст белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 20 | Б.с. үстерү. Мөстәкыйль эш. Мәкальләрне генә аерып язу | 1 | | Мәкальләрне табу һәм әйтемнәрдән аера белү күнекмәсен үстерү | Танып белү активлыгын үстерү |
| 21 | «Аю белән бабай» әкиятендә каршылык (күнегү) | 1 | | Катлаулы каршылык төшенчәсен үзләштерү | Кыскартып сөйләү күнекмәсен үстерү |
| 22 | «Төшеңне сөйлисеңме?» әкиятендә каршылык (күнегү) | 1 | | Өлешләргә бүлү | Гомумиләштерү күнекмәсенн үстерү |
| 23 | Мәзәкләрдә каршылык | 1 | | Мәзәк турында төшенчә формалаштыру. «Иген», «Сарык» һәм Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләрдә каршылык табу | Иҗади күзаллау күнекмәсен үстерү |
| 24 | .Мәзәкләрдә каршылык (күнегү) | 1 | | «Бау», «Борынга салкын тию», «Озын таяк» мәзәкләрендә каршылык табу | Анализ ясау күнекмәсен камилләштерү |
| 25 | Ш.Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигырендә каршылык (күнегү) | 1 | | Әсәрдә каршылык табу | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәләрен үстерү |
| 26 | Б.с.үстерү. Иҗат эше. Ирекле темага әкият язу | 1 | | Әкиятнең өч үзенчәлеген истә тотып иҗат итү | Бәйләнешле,эзлекле итеп язу күнекмәләрен үстерү |
| 27 | М.Җәлилнең «Су төбендә» шигдә каршылык (күнегү) | 1 | | Бөтеннең үз эчендә каршы якларга бүленүе ярдәмендә анализ ясау | Бәяли белү күнекмәләрен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Сыйфат дәрәҗәсе төре буларак халык җырлары | 1 | | Хис дәрәҗәсен табарга һәм аңларга булышу | Җавапны дәлилли белү күнекмәләрен үстерү |
| 29 | Хиснең сәбәбенә багышланган дүртьюллыклар. | 1 | | Аерылу турындагы дүртьюллыкларда хиснең сәбәбен табу | Танып белү активлыгын арттыру |
| 30 | Юануга багышланган дүртьюллыклар | 1 | | Хис өлешләрен  билгеләү | Хис өлешләрен билгеләү, күнекмәләрен үстерү |
| 31 | Халык җырларында хиснең дәрәҗәсе, сәбәбе, юану өлешләре | 1 | | «Ак ука белән кара ука» җырында хиснең өлешләрен табу | Йөгерек,сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү. |
| 32 | Б.с. үстерү.Мөстәкыйль эш: халык җырларында хис өлешләрен билгеләү | 1 | | Укытучы тәкъдим иткән дүртьюллыкларга анализ ясау | Мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерү |
| 33 | Бәетләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре.  170 нче бит | 1 | | Бәет турында төшенчә формалаштыру. »Тоткын Сөембикә бәете»ндә сыйфат дәрәҗәсен билгеләү | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәсен үстерү |
| 34 | Мәзәкчәләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре | 1 | | Мәзәкчә турында төшенчә формалаштыру. «Ике дус», «Тәнкыйтьче», «Ике ялганчы» мәзәкчәләрендә сыйфат дәрәҗәсенең төрләрен билгеләү | Үз эшеңне бәяли белү күнекмәсен камилләштерү |
| 35 | Шигырьләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре | 1 | | Бари Рәхмәтнең «Алтын безнең җир», Н. Думавиның «Бака илә үгез» шигырьләрендә сыйфат | Йөгерек, сәнгатьле уку күнекмәсен камилләштерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | дәрәҗәсенең төрләрен табу күнекмәсен форм-ру | |
| 36 | Әкиятләрдә сыйфат дәрәҗәсенең төрләре. 191 нче бит | 1 | | «Патшаның яңа киеме» әкиятендә сыйфат дәрәҗәсенең төрләрен табу | Кыскартттып сөйләү күнекмәсен үстерү |
| 37 | Г. Тукайның «Бәйрәм бүген» шигырендә кабатлау алымы | 1 | | Кабатлау алымының әһәмиятен ачыклау | Кабатлап уку күнекмәсен үстерү |
| 38 | Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә кабатлау алымы (күнегү) | 1 | | Кабатланган урыннарның узара бәйләнешен табу | Сәнгатьле уку күнекмәсен кам-рү |
| 39 | Б.с.ү. Контроль эш №1: сәнгать алымнары | 1 | | Сәнгать алымнарын гомумиләштереп кабатлау | Мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерү |
| 40 | Табышмаклар. Аларның төзелеше | 1 | | Табышмаклар турында төшенчә формалаштыру | Иҗади күзаллау күнекмәсен үстерү |
| 41 | Метафора. Ф. Сафинның «Очты-китте яшелең» шигырендә мета-фора | 1 | | Метафора, образ атамаларын ачыклау | Дәреслек белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 42-44 | Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясендә метафора | 3 | | Метафора ярдәмендә яңа эчтәлек табарга өйрәнү | Кыскарту, гомумиләштерү күнекмәләрен үстерү |
| 45 | Б.с. үстерү.Сочинение «Нәҗипнең кичерешләре» яки «Үкенү» | 1 | | Эзлекле,бәйләнешле итеп язу күнекмәләрен үстерү | Грамоталы итеп язу күнекмәләрен үстерү |
| 46 | М. Әгъләмовның «Тургай» шиг-дә метафора (күнегү) | 1 | | Метафораны табу ысулларын формалаштыру | Тема буенча фикерләү ысулларын камилләштерү |
| 47 | Р.Фәйзуллинның «Таң», М. Гафуриның «Гомерем йомга-гы» (174 нче бит) | 1 | | Сәнгатьчә фикерләү алымна-рын үзләштерү | Иҗади фикерләү күнекмәләрен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | шигырьләрендә метафора (күнегү) | | | | |
| 48 | М.Җәлилнең «Чишмә җыры» шигырендә метафора (күнегү) | 1 | | Шигырьгә анализ ясау | Дәреслек белән эшләү күнекмәләрен үстерү |
| | Хис – әдәби әсәр эчтәлеге | 25 | | | |
| 49 | Хис. Әти-әниләргә мәхәббәт хисе | 1 | | Хис төшенчәсе. З. Туфайлованың «Әни сүзе», С. Габделмәннең «Бер сукыр баланың моң-зары» шигырендә әти-әниләргә мәхәббәт хисен ачыклау | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 50 | Әнигә мәхәббәт хисе | 1 | | Әсәрнең эчтәлеге атамасына аңлатма бирү. И. Юзеевның «Бөркет турында җыр», А.Алишның «Көтмә инде» шигырьләренә анализ ясау | Үз эшеңне бәяли белү күнекмәсен үстерү |
| 51 | «Сак-Сок» бәетендә әни каргышы | 1 | | Хис ярдәмендә эчтәлек табарга өйрәтү | Фикерләү ысулларын камилләштерү |
| 52-53 | Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясендә әнине ярату хисе | 2 | | Бер үк хиснең төрле эчтәлеге | Иҗади фикер алымнарын үстерү |
| 54 | Әтигә мәхәббәт хисе | 1 | | Р. Фәйзуллинның «Минем әти», М. Җәлилнең «Мәхкүм» шигырендә хиснең өлешләрен табу | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 55 | И.Иксанованың «Әни», К. Булатованың «Ана шатлыгы» | 1 | | Күнекмәсен үстерү | Сорауга тулы җавап бирү күнекмәсен камилләштерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | шигырендә әнигә мәхәббәт хисе (күнегү) | | | | |
| 56 | Ф. Хөснинең «Малай белән солдат» хикәясендә этигә мәхәббәт хисе (күнегү) 219 бит | 1 | | Эчтәлек табуда метафора, каршылык алымнары | Кыскартып сөйләү күнекмәсен үстерү |
| 57 | Б. с. үстерү.Сочинение «Минем әни», «Минем әти» | 1 | | Сочинение язу таләпләре | Иҗади фикерләү сәләтен үстерү. Грамоталы итеп язу |
| 58-59 | Һади Такташның «Мокамай» шигырендә дуслык хисе | 2 | | Дуслыкка тугрылык төшенчәсе | Метафораның вазифасын үзләштерү |
| 60 | Х. Туфанның «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар» шигырендә дуслык хисе (күнегү) | 1 | | Әсәрнең эчтәлеге | Текст белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 61 | Ш. Галиевнең «Рәхмәтләр хакында» шигырендә дуслык хисе (күнегү) | 1 | | Кабатлау алымы аша әсәргә анализ ясау | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 62 | «Алтын балдак» әкиятендә дуслык хисе | 1 | | Охшаш вакыйгаларны берләштерү, исем бирү | Гомумиләштерү күнекмәсен үстерү |
| 63 | « «Турай батыр» әкиятендә дуслыкка хыянәт | 1 | | Гипербола турында төшенчә бирү. Каршылык ярдәмендә әкиятне өлешләргә бүлү | Әкиятнең эчтәлеген табу күнекмәсен үстерү |
| 64 | Кл.тыш уку. «Таңбатыр» әкиятендә туганнарга хыянәт | 1 | | Әсәрне өлешләргә бүлү, өлешләр арасында бәйләнеш | Мөстәкыйль эшләү күнекмасен үстерү |
| 65 | Туган илгә мәхәббәт хисе | 1 | | Туган ил төшенчәсен ачыклау. Х. Туфанның «Аралагыз мине», Н. Мадьяровның «Кышкы әкият» | Лирик әсәр эчтәлеген табу күнекмәсен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | шигырьлләрендә туган илгә мәхәббәт хисен ачу | |
| 66 | Һ. Такташ шигырьләрендә туган якка мәхәббәт хисе | 1 | | «Урман», «Пи-би-би…» шигырьләрендә мәхәббәт хисенең сәбәбе | Лирик әсәр эчтәлеген табу күнекмәсен үстерү. Иҗади фикерләү сәләтен үстерү |
| 67 | Туган якка мәхәббәт хисе | 1 | | М. Әмирнең «Агыйдел», Ф. Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә» (156 б) әсәрләрендә лирик герой хисләренә исем бирү | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 68-69 | Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасында туган илгә мәхәббәт хисе | 2 | | Каршылык ярдәмендә әсәрне өлешләргә бүлү | Хәсрәт хисенең сәбәбен ачыклау |
| 70 | Б. с. үстерү. Сочинение «Ерак китсәм,мин туган ягымны ни өчен сагыныр идем?» | 1 | | Сочинение язу таләпләре | Иҗади фикерләү сәләтен үстерү. Грамоталы итеп язу |
| 71 | Зыя Мансурның «Кырмыска», Н. Мадьяровның «Әби күзлеген эзли» шигырьләрендә игелеклелек | 1 | | «Әхлак» төшенчәсе | Укылган әсәрләр эчтәлегеннән сабак ала белү күнекмәсен үстерү |
| 72 | Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясендә игелеклелек. 203 нче бит | 1 | | Әсәр эчендәге бәйләнешләр. Хис һәм әхлак | Йөгерек уку күнекмәләрен үстерү |
| 73-75 | Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә гаделлек | 3 | | Персонаж бәясе һәм автор бәясе турында төшенчә бирү. | Гомумиләштерү күнекмәсен кам-рү |
| | | | | Әсәрдәге охшаш вакыйгаларны берләштерү, исем бирү | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 76-78 | Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрендә гаделлек | 3 | | Әсәрдәге ике Тукайны аера белү: бала Тукай һәм шагыйрь Тукай | Төп фикерне аера белү күнекмәсен үстерү |
| 79 | Б. с.үстерү. Сочинение «Исемдә калган бер вакыйга» | 1 | | Сочинение язу таләпләре | Иҗади фикерләү сәләтен үстерү. Грамоталы итеп язу |
| 80-82 | Дәрестән тыш уку. Ә. Фәйзинең «Кечкенә Апуш» әсәре | 3 | | Өстәмә чыганаклар белән эш. Конспектлаштыру тәртибе | Мөстәкыйль уку күнекмәсен үстерү |
| 83 | Мифлар «Тавык», «Песи», «Су иясе» | 1 | | Мифларга билгеләмә, анализ ясау үзенчәлеге | Иҗади фикерне күрә белү күнекм-ен үстерү |
| 84 | Мифлар.»Нәркәс чәчәге», «Дөреслек», «Алып кешеләре» | 1 | | Мифларның эчтәлеген табу | Өстәмә чыганаклар белән эшләү күнекмәсен камилләштерү |
| 85-86 | «Ак бүре» әкиятенә анализ. (күнегү) | 2 | | Әкиятнең үзенчәлекләре | Кыскартып сөйләү күнекмәсен үстерү |
| 87 | Х. Халиковның «Болытлар», Ш. Галиевнең «Борау» шигырьләренә анализ (күнегү) | 1 | | Шигырьгә анализ | Сәнгатьле, йөгерек уку күнекмәсен үстерү |
| 88 | И. Гази «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясенә анализ (күнегү) | 1 | | Хикәягә анализ ясау | Үз эшеңне бәяли белү күнекмәсен үстерү |
| 89-91 | Г.Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясенә анализ (күнегү) 205 нче бит | 3 | | | Алган белемнәрне кул-лана белү күнекмәсен үстерү |
| 92 | Дәрестән тыш уку. «Кәҗә белән Сарык» әкияте | 1 | | Өстәмә чыганаклар белән эш. Конспектлаштыру тәртибе | Уку тизлеген үстерү |
| 93 | О.Генриның «Соңгы яфрак» хикәясе (күнегү) | | | Хикәягә анализ ясау күнекмәсен ныгыту | Уку тизлеген үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 94 | Б.с.үстерү.С. Хәкимнең «Күз» шигыре буенча мөстәкыйль эш. Я. Әбдрәхимова «Әдәбият дәресләрендә мөстәкыйль эшләр» 14 бит | 1 | | Мөстәкыйль анализ ясау | Иҗади фикерләү сәләтен үстерү |
| 95 | М. Җәлилнең «Кышкы шигырь» әсәрендә каршылык (күнегү) | 1 | | Каршылыкка хас үзенчәлекләрне аерып әйтә белү күнекмәсен үстерү | Үз эшеңне бәяли белү күнекмәсен үстерү |
| 96 | «Җибәрсем килми җанымдин» халык җырында сыйфат дәрәҗәсе (күнегү) | 1 | | Сыйфат дәрәҗәсе | Сыйфат дәрәҗәсен белү күнекмәсен үстерү |
| 97 | Зыя Мансурның «Суык» шигырендә кабатлау (күнегү) | 1 | | Кабатлау алымының роле | Текст белән эшләү күнекмәсен үстерү |
| 98 | Г. Тукайның «Иссез чәчәк» шигырендә метафора. (күнегү) | 1 | | Метафораны табу | Сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү |
| 99 | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | | Сәнгать алымнары | Гомумиләштерү күнекмәсен үстерү |
| 100 | Б. с. үстерү. Контроль эш № 2: үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | | Алган белемнәрне практикада куллана белү | Грамоталы итеп яза белү күнекмәсен усткрү |
| 101 | Хаталарны төзәтү өстендә эш | 1 | | | Үз эшеңнә анализ һәм бәяли белү күнекмәсен үстерү |
| 102-105 | Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Яңа уку елына әдәбият исемлеге тәкъдим итү | 3 | | Белем алуда системалылык | Белемнәрне системага сала белү күнекмәсен үстерү |

## Сочинениеләрне бәяләү

| № | Эшнең эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1 | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; план буенча (я плансыз) эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган | 1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар | «5»ле билгесе куела |
| 2 | Язманың эчтәлеге темага нигездә туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклегендә артык әһәмиятле булмаган бозу сизелә; теле бай, образлы; стиль, бердәмлеге сакланган | 2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар | «4»ле билгесе куела |
| 3 | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз кулана; бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән | 3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар | «3»ле билгесе куела |
| 4 | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк | 7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгыш бар | «2»ле билгесе куела |

## Язма эшләр графигы
## 5 класс

| № | Төре | Вакыты<br>Пл.   Ф. |
|---|---|---|
| 1 | Б.с.үстерү. Иҗат эше:  әкиятнең дәвамын язу | |
| 2 | Б.с. үстерү. Мөст.эш. Хикәяне әйтемнәр белән баетып язу | |
| 3 | Б.с. үстерү. Мөст.эш. Мәкальләрне генә аерып язу | |
| 4 | Б.с.үстерү. Иҗат эше: ирекле темага әкият язу | |
| 5 | Б.с.үстерү. Мөст. эш: халык җырларында хис өлешләрен билгеләү | |
| 6 | Б.с.үстерү. Контроль эш № 1: сәнгать алымнары | |
| 7 | Б.с. үстерү.Сочинение «Нәҗипнең кичерешләре» яки «Үкенү» | |
| 8 | Б. с. үстерү.Сочинение «Минем әни», «Минем әти» | |
| 9 | Б. с. үстерү. Сочинение «Ерак китсәм,мин туган ягымны ни өчен сагыныр идем?» | |
| 10 | Б. с.үстерү. Сочинение.»Исемдә калган бер вакыйга» | |
| 11 | Б. с.үстерү. Мөст. эш: С.Хәкимнең «Көз» шигыре буенча | |
| 12 | Б. с. үстерү. Контроль эш № 2: үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | |
| | | |

**Әдәбият исемлеге**

— А.Г.Яхин. Әдәбият. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, «Мәгариф», 2006.
— «Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программасы» (Төзүче-авторы:А.Г.Яхин), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011.
— Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов. «Татар әдәбияты. Теория. Тарих». Казан, «Мәгариф», 2006.
— Әдәбият белеме сүзлеге. Казан, «Мәгариф», 2010.
— Ф.М.Хатипов. «Әдәбият теориясе». Казан, «Мәгариф», 2006.
— Д.Ф.Заһидуллина «Урта мәктәптә әдәбият укыту». Казан, «Мәгариф», 2007.
— А.Г.Яхин. «Әдәбият дәресләре». Казан, «Мәгариф», 2005.
— Я.Әбдрәхимова «Әдәбият дәресләрендз мөстәкыйль эшләр». Казан, «Мәгариф», 2002.
— Мәкальләр. Казан, «Мәгариф», 2004.
— Татар поэзиясе антологиясе. « Казан, «Мәгариф», 2002.
— Балачак әдипләре. Казан, «Мәгариф», 2010.
— Татар совет язучылары. Казан, «Мәгариф», 1992.
— Татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com)
— Төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр.
— Белешмә материаллар.
— Балалар өчен чыгарылган газета һәм журнал басмалар.
— Интерактив тикшерү программалары.

**Кулланылган чыганаклар:**

1. Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы Коллегия утырышының 2014 нче ел, 2нче февраленнән 41 нче карары.

*2. «Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон* - Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 № 273-ФЗ

3. Гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары концепциясе – Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования: / под ред.А.М.Кондакова, А.М.Кузнецова – М.: Просвещение, 2009.

4.Гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше концепциясе- Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В.В.Козлова, А.М.Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.

5.Россия Федерациясе гражданины шәхесенең рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү концепциясе – Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина Российской Федерации: / под ред.А.Я.Данилюк, А.М.Кондаков. – М.: Просвещение, 2009.

6.Примерные программы начального общего образования – Гомуми башлангыч белем бирүдә өлге программа эчтәлеге (М.Просвещение, 2009, 2010).

7. Примерные программы основного общего образования – Гомуми төп белем бирүдә өлге программа эчтәлеге. Әдәбият – Литература (М.Просвещение, 2010, 2011).

8.«Әдәбият» уку предметы буенча гомуми төп белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәлелеге.

9. Анисимов О.С. Концептуально-технологические идеи в развивающем обучении и методология. –Уфа-Москва, 2000.

10. Рахимов А.З. Принципы психодидактики. –Уфа, 2007.

11. Яхин А.Г. Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә альтернатив дәреслекләрдән әдәбият укыту программасы. 1-4 нче сыйныфлар.-Казан: Тат .кит.нәш., 2010.

12. Яхин А.Г. Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә альтернатив дәреслекләрдән әдәбият укыту программасы. 5-11нче

сыйныфлар. – Казан: Тат .кит.нәш., 2008.

13. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.

14. Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел; II том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел.

15.Русско-татарский словарь: Под редакцией Ф.А.Ганиева. 4-е изд.,испр. – М.: ИНСАН, 1997.

Искәрмәләр өчен

**«ӘДӘБИЯТ» ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ**

**Татар әдәбияты буенча башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр**


Кәгазь форматы 60x84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Шартлы басма бит 5 Тираж 1000
Корректор: Р.С. Гыйниятуллина
Техник мөхәррир: А.В.Некратова

Оригинал-макет Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының редакцияләү, нәшер итү бүлегендә әзерләнде

420015. Казан, Зур Кызыл урам, 68.